

АЗАТ ХАТЫН

1926 ЕЛДА ЧЫГА БАШЛАДЫ

МАРТ • 1978



САГЫНАМ

Рәшит **АБДУЛЛИН** музыкасы

Разил **ВӘЛИЕВ** сүзләре

Салмак

Тә-рәз кар-шым-да-гы ө-ян-ке-ләр си-нең ке-бек ак шәл я-бын-ган. Си-нең чә-чең төс-ле ак җил туз-гый-мин кыш-лар-да си-не са-гы-нам. Си-нең чә-чең төс-ле ак җил туз-гый-мин кыш-лар-да си-не са-гы-нам.

Кабатлау өчен. Тәмамлау өчен.

Ка-

Тәрәз каршымдагы өянкеләр
Синең кебек ак шәл ябынган.
Синең чәчең төсле ак җил тузгый —
Мин кышларда сине сагынам.

Карашыңдай җылы, аяз көннәр,
Җилләр исә синең ягыңнан.
Гөрләвекләр булып кайтыр идем...
Мин язларда сине сагынам.

Бөтен дөнья бүген шау чәчәктә...
Арынган җир хәсрәт-кайгыдан.
Шатлык төяп кайтып килер идем...
Мин җәйләрдә сине сагынам.

Синең сагыш әллә күчкән инде? —
Урманнарга сары кабынган.
Күзләремдә яшьме, яңгырмы ул?
Мин көзләрдә сине сагынам.

Офыкларга карап һәр көн саен
Сине уйлыйм, сиңа табынам.
Бөтенләйгә тиздән кайтырмын күк —
Сине, әнкәй, сине сагынам.

СОВЕТ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНА ДАН!



**КПССның XXIV һәм XXV съездлары делегаты,
КПССның Үзәк Ревизия комиссиясе члены,
ТАССР Верховный Советы депутаты,
хатын-кызларның хезмәте һәм көнкүреше,
аналарны һәм балаларны
яклау мәсьәләләре буенча
Татарстан АССР Верховный Советының
даими комиссиясе председателе
Галина Павловна ЛОЦМАНОВА
безнең сорауларга җавап бирә**



КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНЫЧ

— Сез, халыкның ышанычын казанган зур вәкиле буларак, бик җаваплы һәм мөһим эшләр башкарасыз. Шул ук вакытта сез — гади эшче. Шулай булгач, сез партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан халык турында нинди кайгыртучанлык күрсәтелгәнен дә, кешеләрнең, аерым алганда хатын-кызларның, моны ничек кабул иткәнен дә яхшы беләсездер. Совет хатын-кызларына хас уй-хисләрнең иң зурысы, иң мөһиме, сезнеңчә, нинди!

— Бу сорауга җавап бирер алдыннан, Конституция проектына кертелгән төзәтмәләрнең берсен искә төшереп үтәсе килә. 35 нче статья проектта менә болай дип башлана иде: «СССРда хатын-кызлар ирләр белән тигез хокуклы». СССР Верховный Советы тарафыннан кабул ителгән Конституциядә ул: «СССРда хатын-кызлар һәм ирләр тигез хокуклы»,— дип язылган.

Беренче карашка аерма зур түгел кебек. Ләкин төптәнрәк уйлап карыйк әле: «хатын-кызлар ирләр белән тигез хокуклы» дисәк, монда әле бүгенге көндә хатын-кызларның хокуклары ирләрнекеннән кимрәктер, дип уйларга урын кала. Совет кешеләре бу мәгънәви үзенчәлекне тоеп алдылар һәм статьяны «хатын-кызлар һәм ирләр тигез хокуклы» дип үзгәртергә кирәклеген әйттеләр. Һәм бу хакыйкатькә ныграк туры килә. Чыннан да, безнең илебездә хатын-кызларның ирләр белән тигез хокуклы булуы күптән инде тормышка ашырылган. Без һәрберебез моны тоеп, шуңа нигезләнеп яшибез һәм, табигый, шулай булырга тиеш, дип уйлыйбыз.

Хәлбуки, тигез хокуклар алу хәтта алдынгы дип саналган капиталистик илләрнең хатын-кызлары өчен дә бүгенге көндә хыял гына булып кала әле. Мәсәлән, АКШ хатын-кызлары ирләр белән тигез хокуклы булу турында төп Законга төзәтмә кертү өчен инде ярты гасыр буе тартышалар, әмма бүгенгә кадәр теләкләренә ирешә алганнары юк.

Хокукларның тигез булмавы көндәлек тормышта да һәрвакыт үзен сиздереп тора. Капиталистик илләрдә хатын-кызларга бер үк хезмәт өчен ирләрдән кимрәк эш хакы түләнә. Мәсәлән, Англиядә, Италиядә, Бельгиядә, Японийдә хатын-кызлар, ирләр белән чагыштырганда, эш хакын 50—80 процент кына алалар. Кагыйдә буларак, ул илләрдә хатын-кызлар иң кара, авыр эшкә алыналар һәм эшсезлеккә иң беренчеләрдән булып дучар ителәләр.

Бу хәлләргә күз салганнан соң, үзебезнең язмышка тагын да ныграк куанасың. Совет хатын-кызларының хокуклары, Төп Законда язылу белән бергә, ныклы гарантияләнә, аларга барлык хокуклардан файдаланырга мөмкинлекләр тудырыла. Безнең кызларыбыз егетләр белән бер үк уку йортларында укыйлар, белем, һөнәр алалар. Юл уңаеннан әйтеп үтик, хөкүмәт бер укучыны бер ел укыткан өчен мәктәптә — 150 сум, техникумда — 640 сум, һөнәр училищесында — 580 сум, университетта — 1000 сум акча тота.

Безнең илебездә хатын-кызлар иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә гаять зур роль уйныйлар. Җирле Советларда депутатларның яртысы диярлек хатын-кызлар, СССР Верховный Советында да мандатларның өчтән бере — алар кулында.

Болар барысы да безнең хатын-кызларыбызга тормышта ныклы ышаныч белән яшәргә мөмкинлек бирә. Алар партиябезгә, хөкүмәтебезгә ышаналар, үз көчләренә ышаналар, киләчәкнең якты буласына ышанып яшиләр. Совет хатын-кызларының күңелен биләгән иң зур хис — ышаныч, дияр идем мин.

— Хатын-кызлар җәмгыятьтә — эштә һәм иҗтимагый тормышта — ирләр белән бертигез хокукта булсалар да, аларның гаиләдәге урыны көнкүрештә үзләренә генә хас мәшәкатьләр һәм кыенлыклар тудыра. Боларны җиңү өчен күрсәтелгән ярдәм турында сез нәрсә әйтә аласыз!

— Совет кешесе турында күрсәтелгән гомуми кайгыртучанлык хатын-кызларның көнкүреш мәшәкатьләрен дә җиңеләйтә, билгеле. Эш хакын арттыру, торак белән тәэмин итү, пенсия түләү, хезмәт кешесенә ял итәргә мөмкинлекләр тудыру, сәламәтлек саклау системасын яхшырту — болар барысы да безнең тормыш-көнкүрешне яхшыртуга китерә. Безнең илебездә сәламәтлек саклауга ел саен 11 миллион сум акча тотыла. 120 мең ясле һәм бакчада 12 миллиард бала тәрбияләнә.


Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

АЗАТ ХАТЫН 3
МАРТ
1978

Иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал.

© «Азат хатын», 1978 ел.

Хатын-кызлар турында кайгырту — ул киләчәк буын турында кайгырту, дигән сүз. Партиябез һәм хөкүмәтебез моңа бик зур игътибар бирә, көнкүреш хезмәтен җиңеләйтү, җәмгать тукланыун яхшырту мәсьәләләре иң югары органнарда хәл ителә.

Соңгы вакытта гына да аналарга яңа льготалар бирелде. Хәзерге вакытта йөкле һәм бала тапкан хатыннарга ял вакытында, эш стажлары күпме булуга карамастан, йөз процент эш хакы күләмендә акча түләнә; авыру баланы карау-тәрбияләү өчен түләүле көннәр саны арттырылды, кереме аз булган гаиләләрнең балаларына пособие түләнә башлады. Хөкүмәтебез шушы чараларга гына да елына өч миллиард ярым сум акча тота.

Бу бишьеллыкта балага бер яшь тулганчы аналарга эш хакының бер өлешен түли башлау күздә тотыла. Яшь балалы аналарның эш сәгатьләрен әкренләп киметү турында Конституциягә язылды.

Әле күптән түгел генә партиябез һәм хөкүмәтебез мәктәп балаларына дәреслекләрне түләүсез бирү турында карар кабул итте.

Предприятиеләрдә хатын-кызларның эш шартларын яхшырту буенча да зур чаралар күрелә.

— Сез хатын-кызларның хезмәте һәм көнкүреше, аналарның һәм балаларны яклау буенча Татарстан АССР Верховный Советының даими комиссиясе председателе. Бу комиссиягә нинди вазифалар йөкләнә һәм ул нинди эшләр белән шөгыльләнә?

— Бу комиссиянең эшли башлаганына әле ел тулып кына узды. Андый комиссияләрнең төзелүе хатын-кызлар турында кайгыртучанлыкның бер мисалы булып тора.

Ел әйләнәсендә без шактый эш тәҗрибәсе туплап өлгердек инде. Сәламәтлек саклау һәм Мәгариф министрлыкларының, Казан шәһәр Советының отчетын тыңладык, «Балалар дөньясы» кибетен, бер бала табу йортын, бер балалар бакчасын тикшердек. Безнең вазифалар бик киң, чөнки хатын-кызларга һәм бала тәрбиясенә кагылышлы барлык мәсьәләләр безне кызыксындыра. Шул ук вакытта кайчак тәҗрибә җитмәү дә үзен сиздерә. Инде хәзер ныгып киләбез, ТАССР Верховный Советы Президиумы безгә бик зур ярдәм күрсәтә. Президиум председателе Салих Гыйлемханович Батыев һәм секретаре Әнисә Шәриповна Мусина белән даими киңәшеп торабыз.

Планнарыбыз бик зур. Чөнки без балалар бакчалары төзү, аларны белемле кадрлар, яхшы сыйфатлы азык-төлек һәм төрле әсбаплар белән тәэмин итүдән алып, фабрикаларда хатын-кызлар эшли торган станокларның гүләвен киметүгә кадәр күп мәсьәләләр белән шөгыльләнәбез. Менә әле шушы арада мех берләшмәсендәге хезмәт шартларын ныклап тикшерергә ниятләп торабыз. Чөнки ул берләшмәдә эшләүчеләрнең күпчелеге — хатын-кызлар. Бер районга барып, авыл хуҗалыгында эшләүче хатын-кызларның тормыш-көнкүреше белән танышырга уйлыйбыз.

Күптән түгел генә оешкан булса да, комиссиянең абруе зур, безнең фикер белән һәркайда исәпләшәләр, тәкъдимнәр һәм сораулар белән бик күп хатлар килә.

— Үз язмышыгыз турында берничә сүз әйтсәгез иде.

— Минем язмышым барлык совет хатын-кызларыныкы кебек бик табигый һәм гадәти. Эшче гаиләсендә туып үстем. Без гаиләдә өч бала, мин өлкәне. Әти-әниемә ярдәм итү өчен, сигезенче классны тәмамлагач, эшкә урнаштым, кичке мәктәптә укыдым, читтән торып техникум тәмамладым. Хәзер дә заводта эшлим, гаилә төзедем, кызым бар. Тырыш хезмәтем өчен хөкүмәтебез мине Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләде.

Кешенең тормышы тоташ сөенечләрдән генә тормый, миңа да кайгы-хәсрәт килмәде түгел. Хезмәт коллективының кайгыртучанлыгын тою миңа ул кайгыларны кичерергә көч бирде.

Хезмәттәшләрем, коммунист иптәшләрем, халкым, съездларга һәм республиканың иң югары органына сайлап, миңа зур ышаныч күрсәттеләр һәм зур вазифалар йөкләделәр. Миңа күп хатлар килә, аларны башка органнарга җибәрмәскә, үзем тикшереп, чарасын күрергә тырышам. Укырга да вакыт табарга кирәк — Югары партия мәктәбендә читтән торып укыйм.

Хатын-кызларга теләгем шул: алар бирелгән хокуклардан һәм мөмкинлекләрдән тулысынча файдаланасыннар, иҗтимагый тормышта кайнап, гомуми эш өчен янып яшәсеннәр иде.

ИНЖЕ

Әминә



аптырап киттe: завод янында бер кеше дә юк иде әле. Проходнойда йокымсырап утырган вахтерларны күргәч, тагын бер кат кул сәгатенә карап алды да, ирексездән стенадагысына күз ташлады. Ялгышкан икән ләбаса! Иртәнге сәгать биш кенә иде әле. Шулай да ул кире борылмаска булды. Каравылчыларның да йокысы бөтенләйгә качсын әле дигәндәй, ишекне киереп ачты да завод ишек алдына атлады... Кыш һәм яз исе катыш һава рәхәт итеп борынны кытыклый. Нәкъ тегe вакыттагыча. Тик аерма шунда: ул чакта 11 класс тәмамлаган унсигез яшьлек кыз завод ишек алдына өйрәнчек булып куркып, борчылып һәм дулкынланып аяк баскан иде, ә хәзер ул югары белемле инженер Әминә Мәҗитовна булып, идарә итүнең автоматлаштырылган системасында бюро начальнигы булып атлый. Курку да юк, борчылу да юк. Дулкынлану гына калган. Моны Әминә бу иртәдә аеруча сизде. Күрәсең, балачактан ук хыялландырган завод булганга шулайдыр ул. Әле салынган чагында ук кирпечләр арасында уйнап үсте ич. Аннан, завод эшли башлагач, эшкә килүче халыкны көн дә диярлек проходной янында озатып кала торган булды.

Эше дә җаваплы шул. Партиянең XXV съездында иптәш Л. И. Брежнев: «Фән-техника прогрессын тизләтү беренче чираттагы бурыч булып кала», диде бит. Аңа, инженер-экономист Әминә Нуруллинага, фән казанышларын кешеләргә хезмәт иттерү бурычы йөкләтелгән. Ә бу исә фән һәм техниканың бүгенге көндә промышленность алдына куйган проблемасын чишү дигән сүз. Аның группасы фәнни-тикшеренү институтлары һәм заводлар белән эш итә. Цехлар алардан информацияләр, производство белән идарә итү планнары алалар.

Әминә җитәкләгән бюро механика һәм җыю цехларына производство заказлары бирә. Цехларның продукцияне вакытында җитештерү һәм озату планын да алар әзерли. Артка калу сәбәпләрен ачалар. План үтәлеше турында рапорт әзерлиләр һәм производство алдында торган башка мәсьәләләрне чишәләр. Шулай итеп, электрон-хисаплау машинасы белән коралланган Әминә группасы йөзәрләгән инженер хезмәтен алыштыра...

Яраткан эштә гел шулай була: Әминәгә дә көн үткәне сизелми калды. Башка инженерлар таралышып беткәч кенә, бүген Актерлар йортында сәнгать буенча лекция буласын исенә төшереп, киенә башлады. Проходнойда аны Берәү көтә иде.

— Культура сараена теннис уйнарга барабызмы? — диде егет. Әминә җавап урынына елмайды гына.

Сердәшләр

Беренче эш көне аның хәтеренә нык сеңеп калды. 6 март иде ул. Тәзкирә тездән кар суы ерып заводка килде. Һәм яшь белгечнең иң беренче ишеткән сүзе конструктор Кәүсәрия турында булды. «Кәүсәриягә күрдем... Кәүсәрия әйтте... Кәүсәриягә яңа тема бирәләр икән...»

Кем ул Кәүсәрия! Ни өчен аны шул хәтле үз итәләр! Моның серен Тәзкирә иkenче көнне үк белде. Ул утырган бүлмәгә балкып, елмаеп бер кыз килеп керде. Эшкә чумып утырган инженерлар «дөнь-



Инженер-конструктор Кәүсәрия бу.

НЕРЛАР



Яраткан эштә гел шулай була: Әминәгә дә көн үткәне сизелми калды.

Тәзкирә дә сердәшеннән калышмый.



ярын онытып» керүчегә төбәлделәр.

— Ә-ә, Кәүсәрия...

Кыз бөтенесе белән дә исәнләшеп, туп-туры Тәзкирә янына юнәлде.

— Яшь инженер-конструктор синмени инде ул!

Нәрсә дияргә дә белми аптырабрак калган Тәзкирәгә үз итеп карап алды да, каяндыр урындык табып, янына ук утырды.

— И, җаным, аңлыйм мин сине... Заводка эшкә килгәч, мин кичергәнне кичерәсең син. Күнегерсең — борчылма... Шулай да син миннән бәхетлерәк: кулыңда инженер дипломы, турыдан-туры конструктор итеп эшкә алганнар. Мин техникумнан килгән идем, приборлар тикшерүче үзәк лабораториядә эшли башладым. Важный гына абыйлар-апалар, я безнең яшьтәге үк кызлар лабораториягә киләләр дә приборларын тикшертәләр. И-и, ул конструкторларга кызыгып калган чакларым! И, кара инде, исемеңне сорарга да онытканмын!!

— Тәзкирә мин. Якупова Тәзкирә,— ди яңа белгеч тә Кәүсәриянең үз итүенә сөенеп.

— Исемең матур икән.

Икесе дә көлеп җибәрделәр. Кәүсәрия хәтирәләр сөйләвен дәвам итте: «Инженер — конструкторларга кызыгуым чиктән ашкач, беркөнне үтендем. Мине дә үзегезнең янга алыгыз әле, вак-төяк сызымнарыгызны сызарга да риза, дим. Юк, сеңелкәем, безгә вак-төяк сызым сызучы түгел, югары белемле инженер кирәк, диләр болар. Фән һәм техниканың иң алга киткән заманы, имеш. Авиация институтына йөгердем. Алмадылар. Безнең профильдәге техникумда укымагансыз, диләр. Кичке мәктәпкә кердем. Аттестат алгач, кичләрен йөреп институтның приборлар төзү факультетын тәмамладым...»

Бу сөйләшүдән соң унлаты ел вакыт уза. Завод зурая, берләшмәгә әйләнә, белгечләр саны арта, инженерлар үсә. Тәзкирә белән Кәүсәрия тормышында да үзгәрешләр зур. Икесе дә кияүгә чыкканнар, ана булганнар. Кәүсәрия ире Лирон белән Җәүһәрия һәм Гәүһәрия исемле кызлар үстерә. Тәзкирә белән Фәритнең дә Эдуард белән Аидасы — уку отличниклары.

Конструкторлар тормышында бер нәрсә генә үзгәрми: Кәүсәрия белән Тәзкирә һаман дуслар, сердәшләр. Хезмәтләрендә үзара ярышалар. Инженерлар арасында берсенең исеме телгә алынса, шунда ук икенчесен дә атыйлар.

Беренче категорияле конструктор Тәзкирә басым һәм температура приборлары бүлегендә Щербань Вениамин Иванович җитәкчелегендә эшләве белән дә чиксез горурлана. Берләшмәдә бу бүлек барлык күрсәткечләре буенча да һәрвакыт беренче урынны алып килә. Аларның приборлары турында күп мактаулар әйтелә. «һәр инженерның үз иҗади планы булсын!» дигән өндәмәне дә Вениамин Иванович күтәреп чыккан иде. Берләшмәдә һәр инженерның аерым зачет кенәгәсе булуы да шушы бүлектәге башлангычка бәйле.

Термометрлар бүлеге конструкторы Кәүсәрия Сәлахова да җитәкчесе Александр Петрович Ивановтан бик канәгать. «Ул акыллы җитәкче генә түгел, сизгер дус та, киңәшче дә»,— диләр аның турында. Кәүсәрия үзе унөч төрле яңа прибор уйлап чыгарган. Хәзер ул яңа темасын тәмамлап килә.

Тәзкирә дә сердәшеннән калышмый, яңа ел башыннан ул да тагын яңа теманы үзләштерергә тотынды.



Людмила Райковичка рәхәт булып китте.

Офицер хатыны

Михаил соң кайтты. Арыган. Иң өстендә офицер йолдызлары җемелди. Зәңгәр күзләрендә канәгатьлек, ышаныч. Людмила аш әзерләгән арада, ул креслосында изрәп йокыга да китте...

Латунь детальләр белән эш итүче Мария Мусихина гальваника цехының технология бюросы начальнигы Райковичны: «Ай, рәхмәтләр яусын инде сиңа, Людмила Николаевна! — дип

каршы алды.— Азот кислотасы тыннарыбызны куыра, пары күздән бөрәзлексез яшь агыза иде бит. Син уйлап тапкан яңа эретмәдә рәхәтләнеп эшлибез. Манылган детальләребезнең дә сыйфаты үзгәрде, төсе матурайды. Алтыннан ясалганнар диярсең».

Инженер Райковичка рәхәт булып китте. Кырык тугыз рационализаторлык тәкъдиме арасында бу соңгысы бик кечкенә кебек тоелган иде. Әнә бит ничек мактыйлар. Кешеләрне сөендерү, хезмәтне җиңеләйтү — иң мөһиме.

Ул әкрен генә цех буйлап китте: участокларга тукталды, эшнең барышы белән кызыксынды, кешеләр белән сөйләште. Бу участокта да аның тәкъдиме буенча ясалган җайланма бар.

Элек монда корычтан ясалган җайланма тора иде. Аның белән җәфаланып беттеләр: ярты ай да үтми, сафтан чыга... Эзләнә-уйлана торгач, Людмила Райкович корычны титанга алыштырып карарга кирәк, дигән нәтиҗәгә килә.

Хәзер еллар буе ремонтсыз эшлиләр. Людмила Николаевнаның бу тәкъдиме елына егерме дүрт мең сум экономия бирә.

— Людмила Николаевна, сезне телефонга чакыралар!

Ул эш бүлмәсенә ашыга. Баш инженер цехта башланачак үзгәртеп корулырның технологик процессларга тәэсире белән кызыксына икән.

Цехта озакламый зур яңалыклар булырга тора...


Людмила кайтканда, Михаил бүген дә өйдә юк иде. Ул ашарга пешерде. Институттан улы Валера, университеттан кызлары Ира кайтып керде... Алар инде үз бүлмәләрендә, дәрес хәзерлиләр. Михаил гына һаман күренми.

...Людмила 22 яшьлек зәңгәр күзле, кара чәчле югослав партизанын, сугыш туктагач Советлар Союзында белем алган яшь офицер Милойко Стевановичны, Ростов шәһәрендә үнҗиде яшьлек кыз чагында очратты...

Өйләнештеләр.

Коннәрдән бер көнне хезмәтеннән иртәрәк кайткан Милойко хатынына:

— Людмила, юлга әзерлән, Куйбышев шәһәренә



ЧИТТӘН КӨТМИЧӘ

«Иҗтимагый үсешнең барышына партия үзенең куәтле коралы булган кадрлар политикасы ярдәмендә йогынты ясый».

Л. И. БРЕЖНЕВ.

(КПССның XXV съездында ясаган Отчет докладыннан)

Безнең Вахитов исемендәге колхозны районда «Яшьләр колхозы» диләр. Моңа хезмәт ветераннарыбызның хәтере калмыйдыр. Аларның каладан махсус рәвештә художник чакыртып ясаткан портретлары колхоз үзәгендәге витринага куелган. Уртада — тракторчы булып эшләгән Хәмидә апа Сәләйманованың рәсеме. Сүзне турыдан-туры аннан башлавымның сәбәбе шул: бу елларда үзәктән килгән һәр вәкил — КПСС райкомы хезмәткәреме, язучымы, әллә журналистмы: «авылыгызда профтехучилище бар, нигә анда бер генә кыз да укымый», дип сорый. Дөрес сүзгә җавап юк. Әмма мин, кадрлар турында иң беренче чиратта кайгыртасы кеше, моңа җавап бирергә тиеш. Хөрмәтле Хәмидә апабызның узган хезмәт юлы белән горурланабыз икән, аның эстафетасын алып баручылар булырга тиеш. Бар иде алар, кызганычка каршы, икәү генә. Берсен тракторчы-машинист дипломы алу белән «уңган кыз, батыр кыз булырга тиеш», дип күрше авыл егете «урлап» китте. Киләчәктә профтехучилищега кыз балаларны җитди рәвештә тартырга уйлыйбыз. Чөнки фәнни-техник революция чорында гади генә эштә дә белемсез, техниканы өйрәнмәгән кадрларга таяну кыенлыклар тудыра. Ә моны тормышка ашыру өчен хәзер һәр колхозда да шартлар җитәрлек. Авылда урта мәктәп бар, хуҗалык экономик яктан үсештә. Шуны күздә тотып, без моннан бернечә еллар элек авыл хуҗалыгы белгечләре итеп колхозның үз яшьләрен хәзерләргә булдык. Партком, колхоз идарәсе һәм мәктәп белән киңәшеп, сәләтле һәм тырыш укучыларны колхоз стипендиатлары итеп институтларга һәм техникумнарга озаттык. Яшьләр ышанычыбызны акладылар. Миннәхмәт Нуриевны Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укытып кайтардык. Хәзер ул бездә инженер булып эшли, читтән торып институтта укый. Вакыйф Мөхәрләмовны авыл хуҗалыгы институтына озаткан идек. Югары белемле агроном булып кайтты. Орлыкчылык буенча агроном булып эшләүче Петр Сапонов та элекке стипендиатыбыз. Бүгенге көндә дә институтларда, техникумнарда укучы стипендиатларыбыз шактый. Гөлсинә Хәсәнова, Рафаиль Тимергалиевларны Казан ветеринария институтында укытабыз. Рәсимә Хәбибуллина, Роза Низамиева иптәшләрне Тукай исемендәге авыл хуҗалыгы техникумына озаттык. Сәләтле, яшь бригадирыбыз Малик Григорьевны Лаеш авыл хуҗалыгы техникумына җибәрдек. Чөнки хәзерге комплекслы бригада җитәкчесе булу өчен сәләт һәм тырышлык кына аз. Ул авыл хуҗалыгы белемен үзләштергән, тирән белемле кадрларның берсе булырга тиеш.

Яшьләрне укытабыз, хуплап каршы алабыз. Монысын башкару күңелле дә, җиңел дә кебек. Ә бит партком аларга тиешле юнәлеш биреп, җитди эш тә таләп итәргә тиеш. Зоотехник еш кына үзенең зары белән уртаклаша: «Унынчы бишьеллыкның өченче елына аяк бастык,— ди ул.— Йөкләмәләр бар, аларны арттырып та үтәргә кирәк. Сөтне күбрәк саудырырга, итне мулрак җитештерергә кушабыз. Без елның ел буе шул хакта уйлыйбыз һәм шуның өчен көрәшәбез».

Баш агрономыбыз Мөхәрләмов та максат белән эшли торган, шәп белгеч. Бишьеллыкның икенче елын уңышлы башкарып чыктык. Һәр сыердан 3 мең 250 шәр килограмм сөт савылды, ит тапшыру планын арттырып үтәдек. Монда агрономның да зур өлеше бар. Игенчеләребез, терлекчеләребез дә сыната торганнардан түгел. Рәшидә Габидуллина, Роза Гарипова, Рита Афанасьева кебек орденлы терлекчеләребез, район Почет тактасыннан төшмәүче механизаторларыбыз бар.

Ләкин арада эш булсынга түгел, көн узсынга йөрүчеләр дә очрый. Нәкыйп Йөзмиев, мәсәлән, шофер булып эшли. Кулыннан эш килә, эш хакы шәп. Әмма ялкаулыгы һәм әхлакый яктан аксавы аркасында премияләрдән мәхрүм калгалый. Шуңа үч итеп башка хуҗалыкка күчеп китәргә чамалады, сыер савучы булып эшләүче хатыны Гөлфия Йөзмиеваны эшкә чыкмаска димләде. Без аны вакытында төзәтүне, тормышында уңай борылыш ясауны максат итеп парткомга чакырдык, үгетләдек. Нәтиҗәсен күрербез... Бу иптәшне исеме белән атавыбызның сәбәбе аңлашыладыр. Ул әле безгә ныклап торып «төзәлермен» дигән сүзен әйтмәде.

Яшьләребез армиядән туры колхозга кайталар. Без аларны моңарчы бик матур итеп озата гына идек. Ә хәзер инде тантаналы итеп каршылый да беләбез. Элекке алдынгы механизаторыбыз Ринат Марковны көтеп алдык. Шинелен салырга өлгергәнче, кулына чылбырлы өр-яңа трактор тапшырдык. Шундый егетләребездән берсе Николай Кирил-

кучерәләр... Иртәгә ук,— диде.

Аннан Оренбург шәһәре... Казан...

— Синең туган илне күрәсем килә, Милойко,— ди Людмила иренә...

Ниһаять, Белград вокзалы. Милойконың әтисе, туганнары, партизан дуслары. Яшь аралаш келүләр, сөйләшүләр, искә алулар...

Гүзәл Адриатика! Югославияне коткаручы совет солдатларына багышлап салынган һәйкәлләр.

Людмиланы бик нык дулкынландырганы, сокландырганы совет кешесен хөрмәт итүче, кунакчыл халык булды...

Сискәндереп звонок шалтырады. Ишектә Михаил-Милойко иде.

— Нәрсә, тагын борчылдыңмы! — диде ул көлеп,— офицер хатыны булу ансат кына түгел ул! Җитмәсә, берсеннән-берсе зуррак балаларың да булсын! Үзең дә инженер бул! Әй!!

* * *

Без Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы «Теплоконтроль» производство берләшмәсендә эшләүче инженерларның бары дүртесенә генә туктaлдык. Бирегә барлык инженерларның 57 процентын хатын-кызлар тәшкил итә. Алар арасында орден-медальләр белән бүләкләнгәннәре дә байтак. Депутатлар да бар.

«Теплоконтроль» унынчы бишьеллыкның икенче елын уңышлы тәмамлады. Бу уңышта хатын-кызларның да өлеше зур. Соңгы ике елда гына да инженер хатын-кызлар тарафыннан ел саен меңәрләгән сум экономия бирүче илледән артык рационализаторлык тәкъдимнәре кертелгән. Приборлары кырыклап илгә чыккан «Теплоконтроль» берләшмәсе үзенең барлык хатын-кыз хезмәткәрләре белән горурлана.

КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты Хатына җавап итеп, берләшмәнең барлык инженерлары, эшчеләре 1978 ел планын үтәү өчен социалистик ярыш җәелдерделәр, җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм эшнең сыйфатын күтәрү өчен көрәшне көчәйттеләр.

Рәйсә ЮСУПОВА.

лов быелның азагында кайтачак. Хәлен белешеп, күңелен күтәреп торабыз.

Хатын-кыз кадрларыбыз белән дә горурланыр хакыбыз бар. Зоотехник Зинаида Филиппова, баш бухгалтер Саимә Вәлиуллина, сыйфат инспекторы Мәрьям Гыйльметдинова, авыл Советы секретаре Илһамия Фәхретдинова иптәшләрнең эшләреннән колхоз идарәсе дә, халык та канәгать. Ике Гөлфиябез бар. Икесе дә комсомолка кызлар. Берсе — Хәйруллина Гөлфия. Икенче ел инде авыл Советы председателе булып эшли. Икенчесе — Кәримова Гөлфия. Комсомол оешмасы секретаре. Икесе дә читтән торып техникумда укыйлар.

Әйтергә кирәк, безнең яшьләрдә укырга, үсәргә омтылыш зур. Җәйге, кышкы сессияләр җиттеме, егермеләп иптәшне кайсын Казанга, кайсын Минзәләгә, Чистай техникумнарына озатабыз. Дуңгыз караучы Клара Сәйфиева зоотехниклыкка, Рөстәм Гыйльмуллин ветфельдшерлыкка, Рәшит Мөхәрләмов финансистлыкка укыйлар.

Колхозда коммунистларның һәм партиясез активның политик укуларын оештыруга да әһәмият бирелә. Урта буын кадрлар экономик укуга йөриләр. Сыер караучылар өчен зоотехника түгәрәге оештырылды. Яшьләр мәгариф челтәрендә укыйлар. Яңа елдан башлап СССРның яңа Конституциясен теоретик яктан өйрәнә башладылар. Яңа кадрлар хәзерләүнең перспектив планнары бар. Күптән түгел урта мәктәп укучылары белән очраштык. Без аларга колхозда тиздән 800 баш сыер өчен комплексы ферма төзелеп бетәчәге һәм анда эшләргә оператор савымчылар, ветеринарлар, фельдшерлар кирәклеге турында сөйләштек. Колхозның яңа культура йорты бар. Ул да махсус белемле кадрлар белән тәэмин ителергә тиеш. Режиссерлар, музыкантлар кирәклеге, сәләтле укучыларны колхоз хисабына ветеринария, культура һәм авыл хуҗалыгы институтларына җибәрү турында сүз барды. Кыскасы, алда торган зур планнарыбызны тормышка ашыру өчен акы белемле, оештыру эшенә сәләтле кадрлар кирәк. Аларны үстерү, тәрбияләү турында колхоз партия оешмасы киләчәктә дә зур тырышлык күрсәтәчәк.

Мөхәммәтҗан ИБРАҺИМОВ,
Кукмара районы, Вахитов исемендәге колхозның партком секретаре.

БӘЙРӘМ ТАБЫНЫНА

Тукай районында, КамАЗдан ерак түгел урнашкан бер совхозга исемен ничек килештереп кушканнар! Җисеменә туры килеп тора — «Весенний». Совхозның 24 гектар теплица мәйданы бар. Ул шәһәр эшчеләрен һәм шәһәр төзүчеләрен яшелчә белән тәэмин итә. Совхоз эшчеләре узган ел 4500 тонна яшелчә үстереп 3,5 миллион сум табыш алдылар. Чәчәкләрнең дә нинди-ләрен генә үстермиләр биредә. Ап-ак калл, алсу роза һәм кып-кызыл канәфер чәчкәләре. 30 мең чәчәк үстерәләр. Бу саннар быел тагын да артачак, чөнки бөтен мөмкинлекләр бар, теплицаның мәйданы да 30 гектарга җитәчәк. Бу көннәрдә теплицада кызу эш кайный, бәйрәм табыннарын бизәү өчен уңыш җыялар.



Комсомолка Халидә Сәйфуллина чәчәк үстерергә Тәмте училищесында өйрәнгән.

Ш. Шакирҗанов фотосы



Оренбург яңалыклары

Күптән түгел Оренбург филармониясе каршында татар эстрада бригадасы оештырылды. Аның чыгышын күп авыллар күрергә өлгерде инде.

*Рәсемдә:*Ниссо Мусина бии.

М. Шакирҗанов фотосы.



Игелекле кеше

Сугыштан соңгы авыр еллар иде. Безнең Ташкичү авылына Казан медицина училищесын тәмамлап Ева Мурдуховна Басина килде. Килү белән җиң сызганып эшкә кереште: авыруларны дәвалады, клубта чыгышлар ясады, тиз арада татар теленә дә өйрәнде.

Трахома, корчаңгы авыруларын ул бетерде дисәк тә һич хата булмас. Корчаңгылы балаларны Казанга алып барып, атналар буе үз йортларында тотып, дәвалаттыра иде. Бу игелекле кеше авыл халкының һаман да исендә. Ул хәзер Казанда яши. Быел аңа 50 яшь тула. Бу уңай белән үзенә олы рәхмәтебезне җиткерәсебез килә.

Авыл халкы исеменнән

Гөлсем ЗӘКИУЛЛИНА.
Буа районы, Ташкичү авылы.

1942 нче елда, укытучы комсомолка Мәдинә Раянова кыска сроклы курста укып, оружейник булып, сугыш операцияләрендә актив катнаша башлый.

...1944 нче ел. Польша. Аэродромга, хәрби заданиесен үтәп, самолет кайта. Очучы өлкән лейтенант Зөфәр Фәттахов кабинаны ачуга, аның янына самолетны «юлга» әзерләүче комсомолка ефрейтор Мәдинә Раянова килеп җитә. Очучы аңа: «Молодец, якташ! — ди.— Ату коралларын һәм бомба ташлаткычларын һәрвакыт төзек тотасың! Бурыч һич тоткарлыксыз үтәлә. Рәхмәт!»

Күп вакыт үтми, оружейник Мәдинә тагын: «Самолет хәрби задание үтәргә әзер!» — дип белдерә. Самолет алгы сызыкка юл ала. Өлкән лейтенант Фәттахов, бөтен ату коралларыннан ут ачып, дошман танкларын штурмлый...

Варшаваны азат иткәндә, командованиенең заданиесен үтәгән өчен, өлкән лейтенант Зөфәр Фәттаховны Польша хөкүмәте орден белән, ә оружейник Мәдинә Раянованы «Сугыш кырында атказанганга» бронза медале белән бүләкли. Раяновага Верховный Башкомандующийның тугыз тапкыр рәхмәте белдерелә.

Мәдинә Раянова Украина, Молдавия, Белоруссия һәм Польшаны илбасарлардан азат итешә. Сугышны Берлинда тәмамлап, Башкортстанга кайта. Пенсиягә чыкканчы Миякә районында укыта.

Хәзерге көндә Мәдинә Раянова Стәрлебаш авылында яши. Аның 86 яшьлек атасы, карт коммунист Әбдрәхим Раянов та исән-сау әле. Әбдрәхим ага —



гражданнар сугышында катнашкан кеше. Колхоз төзү хәрәкәтенең ветераны ул. Аларга карасаң, ихтыярсыздан: «Кызы әтисенә охшаган!» — диясе килә.

Әсгать ТАЙМАСОВ.
БАССР, Стәрлебаш районы.

Бөек Ватан сугышы фронтларында ирләр белән иңгә-иң торып хатын-кызлар да илебез азатлыгы өчен көрәштеләр. Алар сафында минем апам — Әминә Булатова да бар иде. Ул фронтка 1942 елның август аенда китте һәм Болгариягә кадәр данлыклы юл үтте. Авыр контузия дә алды. Ул элемтәче иде. Сугыштагы батырлыгы өчен апам Кызыл Йолдыз ордены, «Сугышчан хезмәтләр өчен» һәм башка медальләр белән бүләкләнде.

Сугыштан кайтканнан соң үзенең укытучылык эшен дәвам иттерде. 1963 елда хөкүмәтебез апамны «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләде.

Хәзер апам лаеклы ялда, Алмалык шәһәрендә яши.

Әсгать БУЛАТОВ,
Чирмешән районы, Иске Кади авылы.

Яңа универмаг

Казанда, ике катлы зур мәһабәт бинада яңа универмаг ачылды. Аның якты залларында үзеңә кирәк әйберне иркенләп сайлап алырга бөтен мөмкинлекләр бар, өске катка йөзмә баскычлар — эскалаторлар алып менә. Универмагта сату биш зур бүлектә алып барыла: «Йорт кирәк-яраклары», «Спорт, туризм, сәяхәт өчен кирәк әйберләр», «Хатын-кызлар киемнәре», «Ир-ат киемнәре», «Тегүчигү, кул эше өчен кирәк-ярак», «Бүләкләр». Бирегә 800 сатучы сатып алучыларга 23000 төрле товар тәкъдим итә.

Универмагта сатып алучыларга кием кисү, авыр әйберләрне илтеп бирү, машина чакыру ише, барлыгы 42 төрле хезмәт күрсәтелә.

Шул ук бинада азык-төлек сату кибете — универсам да бар.



Алар Ватаныбыз азатлыгы өчен көрәштеләр



Фатыйма Яхина (сулда) белән Гыйлмегаян Җиһангирова.

1943 ел. Без «Прогресс» артелендә эшли идек. Бер көнне кызлар белән җыелып киңәштек тә гариза язып, хәрби комиссариатка киттек. Тиздән үтенечебезне канәгатьләндерделәр. Без дүрт комсомол кыз: Полина Туламеева, Мария Архипова, Саимә Әминова һәм мин — Гыйлмегаян Җиһангирова — ефәк күлмәкләребез урынына яшел гимнастерка белән юбка, аякларыбызга ботинка кидек. Сугыш кораллары белән эш итәргә өйрәндек, хәрби ант кабул иттек. Көз җиткәндә без Белоруссия ягына юл тоттык...

Каты һава сугышлары бара иде. Безнең 1872 нче зенит полкы батареялары дошманның күп кенә самолетларын бәреп төшерде.

Җиңү көнен без Польшада каршыладык.

Дошманны җиңеп туган якларыбызга кайттык. Казан вокзалында көрәштәш дусларыбыз белән киләчәктә дә элемтәдә яшәргә вәгъдәләшеп аерылдык. Хәзер мин үзем Урта Азиядә яшим. Ирем белән алты бала тәрбияләп үстердек. Өч улым армия сафларында хезмәт итеп кайттылар. Балаларым бик ярдәмчелләр, үзләренә сугыш елларындагы кыенлыкларны сөйлим.

Хәзер кайда икән минем фронтташ дусларым. Алар белән хәбәрләшәсе килә. Бу язмамны укысагыз, җавап язсагыз иде, кадерле дуслар!

Адресым 746214, Туркменская ССР, Чарджауская область, р-н Дейнау, пос. Московск, ул. Чапаева, 13.

1942 нче елның авыр көннәрендә Башкортстанның күп кенә хатын-кызлары, үзләре теләп, фронтка китә. Алар арасында Стәрлебаш районы кызлары да була.

Укытканн җиреннән фронтка киткән Зәкия Якупова, Зәйтүнә Мөгаттарова, Бану Фәйзуллина һәм Мәрьям Гыйззәтуллиналар Сталинград өчен барган көрәшләрдә катнаша. Бер вакыт дошманның күп санлы самолеты Сталинградка якынлаша. Кызлар тылдагы зенит-артиллерия частьларына тиз арада хәбәр җиткерәләр. Вакытында белдерелгән кисәтү аркасында һава сугышы безнекеләрнең җиңүе белән тәмамлана.

Бу бәрелештә Бану Фәйзуллина белән Мәрьям Гыйззәтуллина сугышчан постларында һәлак булалар.

Зәкия Якупова, Зәйтүнә Мөгаттарова белән бергәләп, Ростов өлкәсен, Украина һәм Белоруссияне дошманнан азат итүдә дә катнаша. Илбасарлар тар-мар ителгәч, Зәкия кече сержант званиесендә демобилизацияләнеп илгә кайта, мәгариф системасында бухгалтер булып эшли.

Ире Габделхәй Искәндәров белән өч бала тәрбияләп үстерде. Кызлары Эл-



Рәсемдә: Гөлсем Хәйбуллина (баскан) белән Зәкия Якупова.

фия — Уфада гыйльми эштә, Зәйтүнә Башкортстан авыл хуҗалыгы институтының 5 нче курсында укый. Рәшитләре Совет Армиясендә хезмәт итә. Лаеклы алмашчы итеп тәрбияләгән өчен ата-анага командованиедән рәхмәт хатлары килә.

Гаиләбез тантанасы

Күптән түгел безнең гаиләдә зур бәйрәм булды: Әниебез белән әтиебезнең көмеш туйларын үткәрдек. Авыл халкы да аларны олылый, хөрмәт итә икән.

«Хатларны һәм газета-журналларны вакытында тапшыруың, күңелле хәбәрләр белән уртаклаша белүең, киңәшләрең өчен зур рәхмәт сиңа»,— диделәр кунаклар әнигә.

Ә әтиебез балта остасы. Колхоз каралтыларын да, авыл халкы йортларын да аның балтасы эшләгән. «Алтын куллы син безнең»,— диделәр үзен зурлап.

Без, балалары, барыбыз да әти-әниебезне чын күңелдән яратабыз, бөтен эштә аларга булышабыз. Безне дә дөрес тәрбияләгәннәр алар. Олы абыебыз авылда, туган колхозыбызда тракторчы, икенче апабыз да авылда, сатучы, ә кече апабыз Санисә бухгалтер булып эшли. Өчебез әле мәктәптә укыйбыз.

Бәйрәмнәре белән әти-әниебезне чын күңелдән котлыйбыз, озын гомер, тазалык, шатлык телибез.

Мәңге яшәгез, әтиләр!

Мәңге яшәгез, әниләр!

Балалары ӘМИРОВЛАР.
Пермь өлкәсе, Уин районы, Толбаш авылы.



Аның фәнни ачышы



Медицина фәннәре кандидаты Галимә Фәтхулловна Хәбирова (уңда) медсестралар Гадилә Мөхәммәтҗанова белән Алсу Фәтхрамановага үзенең яңа приборын күрсәтә. Казан травмотология һәм ортопедия институты хезмәткәре Галимә Хәбирова сынган буыннарны ялгауда даими магнитның ярдәменә оста таяна.

М. Шакирҗанов фотосы



Уянып китүгә, түшәм такталарына күзем төште. Андагы һәр ярык, һәр ботак эзе сабый чактан ук күңелгә сеңеп калган. Күп еллар буе сагынып йөреп, ниһаять, шуларны күрә алу бәхетенә ирешкәч, ниндидер тыныч рәхәтлек сиздем. Түшәмсез йортлар булмый, әмма туган йорт түшәме кебек җанга якын һәм үзеңне хуҗа итеп хис иттерә торган ышанычлы түшәм күргәнем юк микән. Әнә стенадан дүртенче такта. Матча кырыенда гына бер ботак эзе болан сурәтен хәтергә төшерә. Дусларыма күрсәтеп, ул боланның горур гәүдәсе турында сөйләгәнем бар, әмма беркем дә аны болан сурәтенә охшатмады. Мин үзем дә элек боланга охшатмый идем аны, әмма соңрак охшата башладым һәм хәзер дә охшатам. Тугызынчы классны тәмамлаган елны Уртакуш урманында күргән идем мин беренче тапкыр чын боланны. Класс белән экскурсиягә барган идек. Нишләптер ул көнне миңа көне буе Сәлимә белән бергә булырга туры килде. Боланны да без икебез генә күрдек. Сәлимәнең боланнан куркып миңа елышуын, ә бераздан соң бер кулы белән минем беләккә, икенчесе белән җилкәмә сарылып, боланнан күзен дә ала алмыйча карап торуын бүген дә оныта алмыйм әле. Минем аяк астында коры ботак сынган тавыш боланны куркыткан иде. Ул, горур башын артка чөеп, безнең якка таба борылды да, сылу сынын сыгылдырып, куак аркылы сикерде. Шул көнне мин гомеремдә беренче тапкыр йокысыз төн уздырдым. Менә шул йокысыз таңда гади ботак сурәтен горур болан сынына охшата башладым. Ә Сәлимә үзе сылулыгы һәм горурлыгы белән минем өчен боланга чагыштырырлык бердәнбер затка әйләнде.

Күп тә узмады, Сәлимә шушы түшәм астына килен булып керде. Әнием аны, миңа дәшкән кебек, йомшак тавыш белән «бәбкәем» дип, ә ул минем әниемне минем кебек үк «әни» дип йөри башлады.

Җил исеп куйды. Тәрәзә каршындагы тупыл яфраклары лепелдәшеп - үзара серләштеләр. Ачык тәрәзәне каплаган ак пәрдә итәкләрен биетеп, өй эченә иртәнге саф һава бөркелеп керде. Каңәфер чәчәк ата башлаган, күрәсең, чык һәм тупыл сагызы исенә кушылып, каңәфер исе дә борынны кытыклый. Тирән тынлык. Тупыл яфраклары җилфердәгән тавыш әллә нинди сихри рәхәтлек бирә һәм ул бөтен тәнгә җәелә. Мин кабат-кабат иркенләп сулыйм. Сулаган саен сулыйсы килә. Гәүдәм җиңеләйгән кебек, буыннарым таралып, тәнем эреп киткән кебек булып китә. Селкенергә дә куркам. Селкенсәм, һавада йөзгән тупыл мамыклары кебек, очып китәрмен сыман тоела. Мондый назлы минутларда гел матур истәлекләр генә хәтергә килә. Әйтерсең лә берсен икенчесе куалый торган кискен вакыйгалар теземе дә юк, дөнья куу кайгылары да беткән. Күңелдә фәкать кичә әнием белән күрешү шатлыгы гына.

Йорт эченә күз йөртеп чыктым. Әнә анда, берүзе өй эчен өч өлешкә бүлеп, зур мич утыра. Мич авызы караган якта — кухня. Анда учак, плитә, казан. Мич каршындагы стена буенда гомере буе ял белмәгән, күп хезмәт итүенә карамастан, какшап та карамаган аш-су хәзерләү өстәле. Стенада, өстәл кырыендагы тартмаларда, мич авызы өстендәге киштәләрдә әнинең гомер буе тоткан аш-су әзерләү әсбаплар. Шушы мич алдында әниемнең ару-талу белмәс куллары әзерләгән ризык үстерде дә инде мине. Алар ничек якын булмасын!

Мич артында — йокы бүлмәсе. Анда әнием хәзер берүзе йоклый. Ул бүлмәне өй түреннән киң шкаф аерып тора. Шкаф белән мич арасында ике генә данә киң һәм җиңел тактадан ясалган ишек. Шкаф ян ягы белән түрдәге өч тәрәзәнең берсен йокы бүлмәсенә, икесен түр якка аера. Бу ике тәрәзә арасында — комод. Комод өстендә —.рам. Рам эчендә мине дөньяга китергән иң кадерле ике кешенең бергә төшкән фоторәсеме. Әни ул рәсемгә, башына калфак киеп, озын чуклы шәл бәйләп, утырып төшкән. Артында әтием басып тора. Кызганычка каршы, мин әтиемне аз гына хәтерлим, аны әнием сөйләве, документлары һәм фоторәсемнәре буенча гына беләм, чөнки ул Ватан сугышында һәлак булган.

Вакыт иртә булуына карамастан, әнием урыныннан торып, чыгып китеп тә өлгергән. Әниемнең йоклап ятканын гына түгел, гомумән, ятып торганын да күргәнем юк, дисәм дә ялгышмам, чөнки ул мин бәләкәй чактан ук, безне яткырмыйча, үзе йокларга ятмый иде, ә без торганда, аның урыны буш була торган иде. Ул мине дә иртә ятарга һәм иртә торырга өйрәтте. «Таң нурын йоклап уздырган кеше бәхетен күрми кала, чөнки бәхет кешегә иртә таңда гына килә», — ди торган иде ул миңа. Ул зарлана һәм офтана белми дисәм дә дөрес булыр. Дөрес, кайчакларда минем аның елаганын күргәнем бар барын, анда да, безне күрүгә, яулык почмагы белән яшен сөртә-сөртә:

— Юк, бәбкәем, берни дә булмады, мин болай гына, нишләптер күңелем тулып китте,— дип, сорашырга ирек бирми иде. Кичә мине күргәч тә, күзләре чыланып, теле көрмәкләнеп китте аның. Анда да ул сер бирмичә:

— Юк, бәбкәем, бу шатлыктан гына,— диде дә йөгерә-йөгерә чәй әзерләргә керешге.

Стенага элеп куйган сәгать бишне сукты. Өй эче назлы моң белән тулды. Ул моң түшәмнәрне, стеналарны, өйдәге барлык әйберләрне сыйпап йөрде, аннан соң аларга сеңеп, акрын гына юкка чыкты. Бу моң өй алдындагы тупыл яфраклары лепелдәгән тавыш кебек таныш, өстәвенә әллә ничек ягымлы да. Туган авыл туган йорттан башланып китсә, туган йорт минем өчен әллә шушы сәгать моңыннан, тупыл яфраклары лепелдәшүеннән башлана инде? Нишләптер, артык якыннар алар минем күңелгә.

Торып, тышка чыгып йөрисем килеп китте. Әмма ялкаулык түгел, назлану хисе урынымнан кузгалырга ирек бирмәде. Яңадан өй эчен күзләп ятуымны дәвам иттем. Бу карауда безнең өебез миңа ничектер бик кечкенә һәм тәбәнәк тоелды. Заманында дусларыма һәм танышларыма, үземнең зур һәм биек йортта туып үскәнемне сөйләп, ихлас күңелдән мактанып йөргән чакларым искә төште. Фикерләрем шул урында өзел-

де. Ишек алдында әниемнең тавышы ишетелде:

— Теп, теп, теп, теп...

Күрмәсәм дә сизеп торам — җимне беренче булып әтәч килеп чукыды. Чөнки, әни тавышына кушылып, әтәчнең мактанган тавышы яңгырады.

Күзем тагы түшәм такталарына төште. Таныш такталар, таныш ярыклар, таныш ботак сурәтләре. Яшь чакта ятланган җырлар кебек хәтергә сеңгән сурәтләр алар. Әнә бу сурәт шүрәле гәүдәсен хәтерләтә, әмма анда шүрәленең бармаклары түгел, ә башы матчага кысылган. Аннан сулдарак төнбоек чәчәге, ә читтәрәк Яңа Җир атавын хәтерләтә



Надыйр АЛЬМЕЕВ рәсеме

торган таныш түгел атау картасы... Түшәм такталары еллар буе бозылмый торган тигез сафка тезелгәннәр дә, язмышларын матчага тапшырганнар. Ә соңгысы, әкиятләрдәге пәһлеван кебек, армый-талмый һәм зарланмыйча, еллар буе аларны күтәреп тора.

Әнә матчада зур җәлпәк башлы, бармак юанлыгындагы кадак. Әни сөйләвенә караганда, мин тугач, бишек эләр өчен тимерче Хәйрулла абзый кагып биргән аны. Мин белгәннән бирле ул кадакта керосин лампасы эленеп тора иде. Тик кече энем тугач кына лампа урынын вакытлыча бишек биләде. Энем бишектән төшкәч, кадакка яңадан керосин лампасы эленсә дә, соңрак аны электр лампасы алмаштырды. Кадак тирәли кара түгәрәк.

— Керосин лампасының гомерлек истәлеге! —,дип уйлап, матчага каккан кадакка һәм кадак әйләнә керосин лампасы көйдергән кара түгәрәккә карап ята идем, өйгә әнием килеп керде. Генералны очраткач үрә ката торган солдат кебек, урынымнан сикереп торып басарга җыендым. Әллә ничек, таңнан бирле эш белән мәшгуль карт әниең алдында, озын гәүдәңне сузып, ялкауланып яту сәламәт ир өчен башка сыйдыра алмаслык әдәпсезлек булып тоелды. Ана күңеле барын да тоя бит — бу юлы да ул минем уңайсызлануымны шунда ук сизеп алды:

— Иртә әле, улым, ят әле, ят, эшең җиңел түгел бит, мондый иркенләп ятарлык иртәләр бик еш тәтеми торгандыр өеңдә, — дип, сөйләнә-сөйләнә, борылып китәргә иде исәбе, мин аны җибәрмәдем:

— Кил әле, әнием, утыр яныма, — дидем. Шуны гына көткән кебек, әнием карават янындагы урындыкка килеп утырды. Мин салмак кына аны баштанаяк карап чыктым: әниемнең өстендә чуар ситсадан теккән озын күлмәк, бизәкле алъяпкыч, башында почмаклап бәйләнгән яулык. Күз төпләрен, маңгайларын вак кына җыерчык баскан. Ул бер кулын алъяпкыч күкрәкчәсе астына салып, икенче кулының баш бармагы белән ияк чокырын сыйпаган сыман итә. Куллары ябык, тире астында кан тамырлары гына түгел, барлык сеңерләре, хәтта сөякләре дә күренеп тора кебек. Ничектер, әниемнең шушы куллары белән гомер буе эшләгән эшләрен бер өемгә өеп, күләмен күрәсем килеп китте. Күз алдына китерү кыен андый өемне: анда күпме юылган кер, пешерелгән аш, чокылган һәм казылган җир, уталган чүпүлән, ташылган йөкләр. Ул үстергән тавык-чебеш һәм ул сауган сөт кенә дә бөтен авыл халкын ел буе ашатырга җитәчәк. Анысы бер хәл. Ә әниеңнең җан җылысын, безгә күрсәткән шәфкатен, безне яшәргә өйрәтү өчен куйган хезмәтен нинди берәмлекләр белән үлчәргә? Ана кеше бит баланы дөньяга алып килүе һәм аны күкрәк сөте имезеп үстерүе белән генә дә үзенә гомерлек һәйкәл сала. Ә мондый кулга ия аналар... Сүз таба алмыйм мин андый аналарның хезмәтләрен бәяләргә!..

Күтәрелеп әниемнең күзенә карадым. Мин авылдан чыгып киткән вакытларда ул күзләр ялтырап тора, күксел зәңгәр иде. Хәзер бераз уңган кебек булсалар да, элеккечә бик зирәкләр һәм, яшьләр күзе кебек, җитезләр. Кыскарган һәм сирәгәйгән керфекле күз кабаклары ешеш ябылып алгаласалар да, ул барысын да күреп өлгерә. Маңгай күзләре түгел алар, күңел күзләре. Алар синең ни эшләгәнеңне дә, ни уйлаганыңны да күрә. Әнә, әни миңа карап, нидер уйлап торды да һәрвакыттагы кебек йомшак тавыш белән:

— Авылга кайткач, яшь чаклар искә төшә ул. Мин кергәндә үзең тирбәлеп үскән бишекне элә торган кадакка карап ята идең, әллә бала чакларыңны сагынасыңмы, улым? — диде.

Әниемнең каз мамыгы кебек йомшак күз карашы, сары май кебек ягымлы тавышы, буыннарны йомшартып, җанымны эретеп җибәрә торган «улым» дигән сихерле сүзе мине — ир уртасы кешене — кинәт балага әйләндерде. Шундук чормадагы бишек белән сиртмә һәм комод актарганда еш кына очраштыргалаган чыбылдык күз алдыма килде. Алар гүя корылып, матчага каккан шул җәлпәк башлы кадакка эленгәннәр. Алай гына да түгел, мин сабый бала икәнмен һәм бишектә ятам, имеш. Әнием, чыбылдыкны ачып, миңа иелә.

— Бәбкәемнең карыны ачкан икән! — дип, кулын суза.

Башымнан берсен-берсе куып, төрле фикерләр үтте. Күңелемне әниемә ихтирам, рәхмәт хисе биләп алды. Ананың бөеклеге һәм гадилеге үзара чормалып, мине сүз таба алмаслык авыр хәлдә калдырды. Үземне әнием алдында беркайчан да һәм берничек тә кайтарып бетергесез бурычлы кеше итеп хис иттем. Мин:

— Хәзер, әнием, торам. Дөнья хәлләрен торгач сөйләшербез! — дигән сүздән башка сүз таба алмыйча, аның кытыршы кулларын сыйпап алдым. Әнием елмаеп куйды:

— Әйе шул, улым, тор, иртә таңда аяк өсте булган кеше бәхетле була! — диде. Әле күптән түгел генә әйтелгән «Иртә әле, ят әле, ят!» — дигән сүзләре мине сынап карау өчен генә булгандыр. Елмаюы шуның билгесе иде.

ЖАН РИШАР БЛОК

Миләүшә МАННУРОВА



Франс Блок ире Фредо Сиразен белән

Без онытылмас истәлекләр белән Париждан Мәскәүгә кайтып килә идек. Тиздән туган ил туфрагына аяк басарбыз. Инде самолет әкренләп түбәнәя башлады. Минем янымда — ике француз. Аларның берсе — яшь егет. Ул әле бер иллюминаторга, әле икенчесенә карый.

— Нинди киңлек, нинди иркенлек, менә Россия нинди икән! — ди.

— Сез безнең илгә беренче мәртәбә киләсезме?

— Әйе, «Дуслык» лагерена барабыз без. Ял итәргә.

— Кайда ул лагерь? Казан янында түгелме?

— Әйе, Казан шәһәре янында, Идел буенда. «Волга» дип атала, — дип җавап бирде ул.

— Мин дә Казанга кайтам бит! — дидем.

Бу көтелмәгән очрашу икебезне дә гаҗәпләндерде. Без сөйләшеп киттек. Ул безнең сәяхәт турында сораша. Мин үземнең Франциядә алган тәэсирләрем турында сөйлим.

Саубуллашканда Польгә яхшы ял итүен теләдем.

Французча белгәнгә, мин «Волга»да ял итүче Франция яшьләре белән булган очрашуларга да катнашып киләм.

Казанның Химиклар культура сараенда совет һәм француз яшьләренең очрашу кичәсе бара иде. Зал рус һәм француз телләрендә язылган лозунглар белән бизәлгән. Рус һәм француз телендә ялкынлы сүзләр, шигырьләр яңгырый. Кинәт минем танышым Поль сәхнәгә чыкты һәм дулкынланып сөйли башлады:

— Сезнең илдә яшьләргә бирелгән хокукларны күреп, аеруча шатланам мин. Без дә сезнеңчә яшәргә телибез. Дуслык элемтәләре безгә моңа ирешергә булышлык итәр! — диде ул.

Шулай без тагын очраштык. Поль миңа истәлеккә Альбер Узульясның «Яшьләр батальоны» исемле китабын бүләк итте. Бу китапта Европа илләре һәм Советлар Союзы яшьләренең сугыш елларында гитлерчыларга каршы алып барган көрәше сурәтләнә. Узульяс үзе дә Франция партизаннары сафында көрәшкән һәм бу чорда аны полковник Андре дип йөрткәннәр.

Язучы үзе яхшы белгән кешеләрнең язмышы турында гына түгел, Зоя Космодемьянская, Олег Кошевой кебекләр, Германиядә Гитлер хөкүмәтенә каршы баш күтәргән яшьләр турында, Франция җирендә көрәшкән немец антифашистлары, поляк, чех, югослав, совет кешеләре турында яза. Китапта француз яшьләре турында материаллар аеруча күп, билгеле. Франс Блок-Сиразенның көрәш юлы мине аеруча дулкынландырды.

Франс Блок-Сиразен күренекле прогрессив язучы Жан Ришар Блокның кызы, химия өлкәсендә эшләүче галим булган.

1940 ел. Франция тарихында иң авыр көннәр. Галим Франс Блок-Сиразен яшерен лабораториядә партизаннар өчен снарядлар, бомбалар ясый. Бу эш Испания сугышларында катнашкан карт немец эшчесенең квартирасында алып барыла. Шул кораллар белән патриотлар отельләрне, немецләр күп җыелган урыннарны шартлаталар. Париж тирәсендә һәм башка урыннарда поездлар шартлату, көпә-көндез немец офицерларын үтерү очраклары күп була. Немецлар, шуңа җавап итеп, бик күп кешеләрне кулга алалар. Шулар арасында Франсның ире Фредо да була.

Альбер Узульяс болай дип яза:

«Мин Парижның бер мәйданында Франс белән очрашырга тиеш идем. Тыйнак, ләкин батыр йөрәкле Франсның йөзе бүген артык борчулы иде. Мин аны кафега алып кердем дә:

— Нәрсә булды? — дип сорадым.

— Фредо төрмәдә. Миңа газеталар кирәк. Анда исемлек булырга тиеш. Заложниклар арасында, бәлки, аның да исеме бардыр... Минем аны ничек яратуымны син беләсең...

Тирән көрсенеп, тагын өстәп куйды:

— Ләкин чигенергә ярамый... Үч алырга кирәк!

Бу хәбәр безнең йөрәкләрне әрнетте. Чөнки фашистларның хәтта гөнаһсыз кешеләрне дә газаплауларын без яхшы белә идек. Андый кешеләрнең безгә: «Сез, исән калучылар, үлемгә хөкем ителгәннәргә лаеклы булырга тиешсез», — дип төрмә һәм концлагерь стеналарына язып калдырган сүзләре генә килеп җитә иде.

Франс Блокның да язмышы аяныч булды. 1942 елда немецлар аны кулга алдылар, Германиягә төрмәгә җибәрделәр. 1943 елның 12 февралендә Гамбургта аның башын чабып үтергәннәр».

Кызы шундый батырлыклар һәм фаҗигалар кичергән елларда Жан Ришар Блок үзе безнең илебездә, Казанда була. Ул кызының хәлен белми, ләкин аның белән бер фронтта була, фашистларга каршы зур көрәш алып бара.

Жан Ришар Блок Россиядәге революцион көрәш белән яшьтән үк кызыксынган кеше. Илья Эренбург әйтүенчә, 1905 елның 9 январенда Франция студентлары Россия студентларына, бик күп имзалар куеп, мөрәҗәгать-хат язалар. Бу хатның әзтләгелән Сорбонна студенты Жан Ришар Блок язган була.

Жан Ришар Блок — романнар, публицистик мәкаләләр, пьесалар, шигырьләр язган әдип. 1911—14 елларда ул буржуаз җәмгыятьнең череп таркалуын күрсәткән «...и компания» исемле романын яза. 1936 елда Испания халкының фашизмга каршы көрәшен чагылдырган «Испания! Испания!» исемле романын иҗат итә.

1934 елда СССРда язучылар съездында катнаша. Безнең илгә аның бу беренче килүе була.

Фашистлар Франциягә басып алгач, 1941 елның апрелендә, ул хатыны белән Мәскәүгә килә. Аларны Илья Эренбург каршы ала. Блок аңа Франциянең хәле турында, прогрессив француз язучыларының фашизм белән килешә алмаулары турында сөйли.

Гитлер Германиясе безнең илгә һөҗүм иткәч, башка антифашист язучылар белән бергә, Жан Ришар Блок та 1941 елның көзендә Казанга килә һәм 1942 елның язына кадәр биредә була, Куйбышев урамындагы 7 нче йортның 1 нче квартирасында тора.

Сугыш елларында ул үзенең үткен каләме белән дошманга каршы көрәшә. Мәскәү радиосы аша французларга мөрәҗәгать итә, шигырьләр укый. Блок совет кешеләренең батырлыгына соклана һәм аларның дошманны җиңәчәгенә ышана:

«Һәм ышана минем күңелем ике халыкка:
Париж халкына һәм Мәскәү халкына», —

дип яза ул «1941 елның Октябре» дигән шигырендә. Сугышның иң авыр көннәрендә дә, фашистлар Мәскәү янына килеп җиткән көннәрдә дә ул өметсезлеккә бирелми. Сугыштан соң аның бу чыгышлары «Оккупацияләнгән Франциядән кораллы Франциягә» дигән китапта басылалар. Шул китабы өчен Жан Ришар Блок (үлгәннән соң) 1950 елда Бөтендөнья Тынычлык Советы премиясе һәм алтын медаль белән бүләкләнә.

Казанда торганда ул «Тулон» исемле пьеса язып бетерә. Әдип анда француз диңгезчеләренең батырлыгын сурәтли. Татарстан Язучылар союзында бу әсәрне тикшерү үткәрелә, әлеге утырышта татар язучылары да катнашалар. Әсәрне Павел Антокольский рус теленә тәрҗемә итә. «Красная Татария» газетасында Жан Ришар Блокның Мәскәү янындагы җиңүләргә багышланган мәкаләсе басыла. Ул Качалов исемендәге театрның антифашистик спектаклен әзерләүдә катнаша, завод, фабрика, госпитальләрдә, Тукай клубында чыгышлар ясый. Шулай итеп, Жан Ришар Блок фашистларга каршы көрәштә туган иленә читтән торып булса да ярдәм итәргә тырыша.

Ачлы-туклы авыр тормыш, көнкүреш уңайсызлыклары, баш күтәрми эшләү дә туган илен сагыну хисен баса алмый. Язучы Франциядә калган балалары, анасы өчен борчыла. Әмма аларның язмышы турында күп вакыт үткәч кенә белә: фашистлар аның кызын гына түгел, 80 яшьлек анасын да үтерәләр — Освенцим мичләрендә яндыралар.

1945 елның январенда Жан Ришар Блок азат ителгән Франциягә кайта. Коммунист язучы прогрессив «Се суар» газетасының редакторы булып эшли башлый һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр көрәшче булып кала.

1947 елда ул кинәт үлеп китә.

Шат күңелле, саф хисле бу кешенең якты истәлеген Казанның күп кешеләре һаман да йөрәкләрендә саклыйлар.

«Кешеләр Җире» дигән китабында Сент-Экзюпери: «Һәркем кешеләрнең гомуми язмышы өчен үзен җаваплы хис итәргә тиеш», — дигән иде. Сугыш вакытында кешеләр бу сүзләрнең мәгънәсен бик яхшы аңладылар, бер максат белән яшәделәр. Ул бөек максат — фашизмны бетерү максаты иде. Жан Ришар Блок һәм аның кызы Франс кешеләрнең гомуми язмышы өчен үзләрен җаваплы итеп санадылар, гомерләрен гаделлек, бәхет, азатлык өчен көрәшкә багышладылар.

ЗАКЛАДЛАРГА САЛГАН МАЛ КҮК...

Октябрь революциясенә кадәр хатын - кызлар сатлык мал урынына йөргән, аларны сатканнар... дигән сүзләрне күп кеше, ихтимал, образлы тасвир, гипербола буларак кына кабул итәдер.

Документлар исә моның чынлыкта шулай булганын сөйлиләр. Әйдәгез, шул заманның — Октябрь революциясе алды елларының тарихи язмаларын актарыйк. Сатылган кызлар, аларны сатучылар, моңа арадаш булган затлар, бу кыргый гадәткә протест белдергән кешеләрнең исемнәрен атыйк. Авылларын, өязләрен күрсәтеп сөйлик...

«Безнең Чүриле волостена да хатын-кызлар белән сату итүчеләр әкрен генә рәхим итә башладылар,— дип яза 1913 елда Сикертән авылы (хәзерге Арча районы) мөгаллиме Сөнгатулла Бәдретдинов.— Бер ел эчендә дүрт барышник күренде. Узган көз Казан өязе Курса авылыннан бер кеше белән шул ук өяз Чокырча авылыннан бер хатын Ташкент ягыннан кайттылар да, берсе Сикертән авылыннан — бер тол хатын, икенчесе Чокырча тирәсеннән унөч яшьләр чамасында бер кыз алып киткәннәр иде.

Менә әле шушы көннәрдә генә Сикертән авылының читтә йөрүчеләреннән Гатаулла Юлдашев дигән кеше белән бер нәмәгълүм кеше кайтып төштеләр дә, тиз-тиз генә шундый артык-портык хатыннарны эзли башладылар. Сикертәннән ике кыз баласы белән бер тол хатынны алып китмәкче булып вәгъдә дә куйдылар. Теге бичара хатын аз-маз акчага алданып, анда баргач бик рәхәткә тиенәсең дигәч, барырга тәмам кызган. Мин хатынга бардым да, эшнең кая барып чыгачагыннан хәбәр бирдем, хатын да минем сүземне җиргә салмады, алар белән китүдән туктады. Алар әле шушы тирәдән эзлиләр икән. Курса авылыннан бер хатынны иярттеләр, ахыры». («Йолдыз» газетасы, 1913 ел, 15 октябрь, № 1047).

Татар кызларын Урта Азия байларына сату гадәткә кергән бер хәл булган икән.

«...Журбай исемле бер казах татар кызларын Төркстанда сатып йөри. 1906 елда ул Түнтәрдән (хәзерге Балтач районы) өч кыз алып китә, шуларның берсен алтмыш яшьлек бер байга 500 сумга сата. 1907 елда ул Закирҗан исеме белән яңадан Казан артына килеп чыга. Закирҗан Урта Азия байларыннан «күп заказлар һәм задаткалар алып килгән. Татар агайлары, фәкыйрьлеккә чыдый алмыйча, моңа кызларын саталар». («Вакыт» газетасы, 1907 ел, № 216).

Газетаның язуына караганда, сатылган кызларның кайберләре хуҗаларыннан качып китәләр, кайберләре фәхешлек юлына керәләр икән.

Тагын бер хәбәр: «Журабай Түнтәр авылына килеп җиткән. Бер кызны никахлап алган, икенчесен атасыннан 25 сумга сатып алган. Тегендә баргач никахлап алганын талак кылып аера да, кыйммәт бәягә сата икән. Сәрдек авылында бу никахның нәрсә икәнен аңлаган агайлар никах мәҗлесенә барганда мулланы тотып алып бик нык кыздырганнар. «Сәүдәгәрләр» Арбордан— ике, Түнтәрдән тугыз — барлыгы унбер кыз алып киткәннәр». («Вакыт», 1907, № 238).

Кыз сату очраклары башка губерналарда да булган. Саратов губернасы, Кузнецк өязе «Б» авылыннан хәбәр итәләр: бу авылдан өч кызны сатып алып киткәннәр. Мәликә — 17 яшьтә, Фатиха — 16, Мәргубҗамал — 15 тә. Боларны иптәш кызлары озата бара, кочаклашып елашалар...

«Никах укыганда кызларның берсе качмак булды,— дип яза газета хәбәрчесе, — әмма барып чыкмады. Балаларның бәясе унбишәр сум иде. Боларны гәзит белән генә тәрбияләп булмый. Кеше сатучыларга прокурор кирәк. Кызның ризалыгыннан башка никах укучыларның, «ул риза» дип шаһадәт бирүчеләрнең бер - икесен башлап хөкемгә гарыз итәргә тиешле». («Вакыт», 1908, № 330).

Ташкент тимер юлындагы Аральское море станциясендә мондый хәл- була. Казан артыннан ике хатын-кызны сатарга китергәннәр дигән хәбәр тарала. Имеш, инде аларны 360 сумга сатканнар да икән. Оренбург ягыннан сәүдә эше белән килгән Габдрахман Галиев бу хәбәр белән кызыксына. Галиевнең приказчиклары сатылган кызларны эзләп китәләр. Тапсалар — йозаклы өй эчендә ике хатын-кыз. Куркышып беткән хатыннар приказчиклар белән башта сөйләшмиләр. Әмма «Казан шивәсен ишеткәч, сөйләп бирәләр». Аларны Казан артыннан бер кеше китергән һәм инде хуҗаларын да күрсәткән икән. Хуҗалар «мал»ны карап, ошатып, килеп алырга вәгъдә итеп өсләреннән бикләп киткәннәр. Приказчиклар властьларны алып килеп ишекне ваталар. Йорттан бер хатын белән бер яшь кыз чыга. Сорашалар. Казан өязе, Бәрәзә авылыннан 26 яшьлек хатын, исеме Маһитап. Яшь баласы белән сатылган. Тегесе — моның сеңелесе, 18 яшьлек, Шәфига исемле. Болар Бәрәзәнең Бәдретдин исемле кешенең кызлары. Сатучының да кем икәнен ачыклыйлар. Казан белән Урта Азия арасында җиңел кәсеп белән көн күрүче егет — Иске Тазлар авылыныкы, исеме — Җәләлетдин. Шома егет кесәсеннән бер кәгазь чыгарып күрсәтә: Бәрәзә имамы Габделгаләм Габделбәдигый үз мөһерен басып «бу кеше әлеге хатыннарны үзе теләгән җиргә урнаштырырга хаклы» дип кәгазь биргән икән. Габделгаләм хәзрәт сатылган хатыннарга метрикадан «выписка» да биргән. Приказчик егетләрнең таләбе буенча властьлар бу кәгазьләрнең барысын да алып Уфага Диния назарәтенә җибәрәләр. Әмма сатылган хатыннарның хуҗалары килеп гауга чыгаралар. Җәләлетдиннән акча таләп итәләр. Шома егет исә 180 сумын (бер хатын бәясен) инде тотып та өлгергән икән. Ул арада башкалар да җыела: Җәләлетдин тагын берничә байдан задатка алган икән. Спекулянтны ничек ычкындырганнардыр, анысы билгеле түгел, әмма Җәләлетдинне һәм Габделгаләм хәзрәтне фаш иткән Оренбург сәүдәгәре өенә кайткач туп-туры газета редакциясенә килә һәм Диния назарәтенең бу эшкә күз-колак салмавына, хәзрәтне әле дә булса җавапка тартмавына ачуын белдерә. («Вакыт», 1908, № 330).

Унынчы елларда Астрахань шәһәре хатын-кыз сату базарының үзәгенә әйләнә. Баку һ. б. шәһәрләргә Астрахань базары аркылы фәхешханәләргә бик күп кыз озатыла. «Хәтта Төркия вә Иран хәрәмнәренә дә шуннан җибәрелә. Бу яман эш белән күбрәк Казан татарлары кәсеп итәләр». Шәһәр интеллигенциясе, прогрессив журналистларның таләбе буенча бу турыда губернатор янында киңәшмә җыела. Киңәшмә карар кабул итә: хатын-кыз сатучыларны, аларны алып китүчеләрне эзәрлекләргә, тотарга. «Алдагы январьда булачак «Хатыннарны химая җәмгыятьләренең» съездында бу мәсьәләнең каралуын вә съездның хөкүмәттән бу хакта шиддәтләрәк тәдбирләр кыйлуын үтенүне таләп итәргә карар бирелде». («Вакыт», 1909, № 540).

Документлар әнә шулай сөйли. Әмма, хатын-кызларны сатлык мал хәленнән бернинди «химая итү» җәмгыятьләре, бернинди киңәшмәләр, карарлар, протестлар коткара алмады. «Закладларга салган мал күк, абау, җаныем, безнең хәл» дип йөрәк ачысы белән җырлаган татар кызын бары тик Октябрь революциясе — бөек тарихи борылыш кына коллыктан азат итте.

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ.

МИН ӘЛЕ ЮЛДА...

Беренче шигырь китабым 1959 елда чыккан иде. Шактый гомер узды, дистәгә якын кечкенә-кечкенә китапларым дөнья күрде, пьесаларым куелды. Кечкенә дим, күбрәк җырлар, лирик шигырьләр язганга, минем китапларым калын түгел.

Шулай, дистәгә якын китабың чыккач, иҗат юлыңа борылып карап, иҗатың хакында йомгак сүзе әйтик, диючеләр дә бар. Мин андый кешеләргә, йомгак ясарга ашыкмыйк әле, дип җавап бирә киләм. Игенчеләр дә уңышны көзен, ашлыкларны кырдан җыеп алгач санныйлар бит. Күңелемдә гел яз, көзгә җилләрне үткәрәсем килми әле. Кар-бураннарга уралып, язгы кояш нурларына сокланып, гел юлда барам кебек. Иҗат юлым дәвам итә. Соңгы вакытларда язган бер бәйләм шигырьләремне укучылар игътибарына тәкъдим итәм.

Гөлшат **ЗӘЙНӘШЕВА.**



Ак чәчәк


Хәйран калдым кырда күреп,
Гап-гади бер ак чәчәк.
Ник моңарчы күрмәгәнмен,
Шул гомер җирдә яшәп?!

Әкрен генә сыйпар идем,
Кагылырга кызганыч.
Шундый гүзәллекне күрми,
Күпме гомер узган ич!

Гомер узган, ә ак чәчәк
Уелып үскән болында.
Ак чәчәк дип юри әйтәм,
Бәгърем, синең турында.

Син ул, бәгърем, саф ак чәчәк,
Таң нурында коенган.
Синдә язгы табигатьнең
Бар сафлыгы җыелган.





Бер сеңелкәшкә

Ни булган бу сеңелкәшкә,
Бер елмая, бер көлә.
Ай янында йолдызмыни,
Йөзеннән нур бөркелә.

Аллы-гөлле яңаклары,
Чәчәк аткан бу сеңел.
Кызларның чәчәк атуы
Тикмәгә генә түгел...

Чәчәк ата кызлар шулай
Язын да, көзләрен дә.
Кара роза кебек серле,
Сеңелкәш, күзләрең дә.

Ни булганын аңлыйм кебек,
И матур сеңелкәшем!..
Мөгаен бардыр, көтәдер
Өзелеп сөйгән кешең!..

Бәхетемә юрадым

Туган җирем, үскән җирем,
Гади генә бер авыл.
Гади булса да, яз җиткәч,
Гөлбакчасы була ул.

Туган авылым урамын
Кабат-кабат урадым.
Баш очымда кош сайрады,
Бәхетемә юрадым.

Авылымның тупылларын
Белмим, кемнәр утырткан.
Карасам, күзем алалмыйм
Сөйгәнем туган йорттан.

Туган авылым урамын
Кабат-кабат урадым.
Баш очымда кош сайрады,
Бәхетемә юрадым.



Урманнарда йөрдем

Урманнарда йөрдем, иркен сулап,
Бигрәк хуш исле нарат ылысы.
Йөрәк ярасын да төзәтәдер
Күз карашкайларның җылысы.

Урманнарда йөрдем җәйге таңда,
Басылмасмы дип сагыш күңелдә.
Кара төнне яктырткан ай шикелле,
Булсаң иде язмышым күгендә.

Урманнарда йөрдем бер ялгызым,
Баласын җуйган болан эзеннән.
Башларым әйләнеп китте кинәт,
Башканы сөям, дигән сүзеңнән.

КамАЗ юллары

Идел булып ага,
Диңгезләргә таба.
Дулкын-дулкын Кама сулары.
Илтсен сине сөйгән ярыңа,
Борма-борма КамАЗ юллары.

Кама буйларында,
Яшьлек елларында,
Хезмәт белән таңнар каршыла!
Сөйгән ярың булып елмаеп,
Бәхет үзе килер каршыңа.

Көймә килә уйнап,
Кама суы буйлап,
Ишетелә яшьлек җырлары.
Язмышларны куша язмышка
Борма-борма КамАЗ юллары.

Хәерле юл теләп
Озата һәр тирәк,
Дулкын сәлам әйтә Иделдән.
Адашмассың, кайда йөрсәң дә,
Юлга чыксаң КамАЗ җиреннән.

Хәбир ӘХМӘТҖАНОВ рәсемнәре



ЧИБӘР КЫЗЛАР КЕЛӘМ ТУКЫЙ



Ай-һай матур келәмнәре, күзнең явын алырлык! Әйтерсең лә ак, кызыл, зәңгәр чәчәкләр сибелгән. Күрү белән үзеңне хәтфә болыннарда, сихри урманнарда кебек хис итәсең.

Кемнәр тукый бу келәмнәрне, кемнәр шулай бәйләм-бәйләм чәчәк үрә, күз нурларын түгә-түгә!

Әллә кайлардан эзләмәгез бу кызларны. Алар башкалабыз Казанда яшиләр... «Таттрикотажбыт» берләшмәсенең келәм цехында эшлиләр. Җанны хушландырырдай бизәкләрне бары тик кызлар кулы гына төшерә ала.

Кызларның кулларына күз иярми. Смена буе җепләрдән төен арты төен бәйләнә. Җиңел түгел — бер квадрат метр келәмдә 40 мең чамасы төен бар. Бөтен келәмдәгеләрен саный китсәң, йөз меңнәргә җыела.

— Ялыкмыйсызмы! — дип сорыйм мин кызлардан.

— Эшен яраткач, ару-талуга бирешмибез,— диләр алар.

Фирдәвескә күз тимәсен, бигрәк җитез — арфа кылларын чиртәмени! (Тукучы Фирдәвес Сиражетдинова фоторәсемгә дә төшерелгән).

Мария Токинованың да Фирдәвестән калышырга исәбе юк. Гүя алар осталыкта ярышалар. Башкалар да сынатмый. Асиясе, Иклимәсе, Сөмбеләсе, Зөлхиҗәсе — барысы да уңган кызлар, барысы да мактаулылар.

Келәм сугу серләренә, бу борынгы һөнәргә кызларны мастер Нина өйрәтә.

— Кызлар тырышлар,— ди ул.— Орнамент төгәл чыксын өчен, келәмчедән зур сизгерлек таләп ителә. (Нина Солосина белән цех начальнигы да еш киңәшә. Фоторәсемдә сез аларны да күрәсез).


Төенле келәм туку участогы нурга тулган. Кая карама — гөлләр! Станоклар гөрләве юк монда. Һәр урында тирән тынлык, җепләр тоткан куллар гына йөгерәләр тукыла торган келәмнәрдә. Күз алдында могҗиза туа, сәнгать әсәре туа.

Хәйран калып карап торам келәмчегә. Чибәркәйләр келәм тукый күңел биреп, йөрәк җылысын җепкә кушып, әбием-әнием һөнәренә гашыйк булып.

Касыйм ТӘХАУ.

Рифкат ЯКУПОВ фотолары.





Раушан **ЯКУПОВА.** «Алмалар».

Матурлык дөньясында

Журналның бу санында сүз хатын-кыз рәссамнарыбызга бирелде. Күргәнегезчә, монда аларның төрле әсәрләреннән алынган күчермәләр урнаштырылган.

Дөрес, Гайшә Рахманкулова иҗаты да, Раушан Якупованың натюрмортлары да, Елизавета Киселева әсәрләре дә, Рада Нигъмәтуллина скульптуралары да укучыларга яхшы таныш. Күпләр, мөгаен, аларның күргәзмәләрендә дә булгандыр, журнал битләрендә моңарчы бастырылган әсәрләренә карап та соклангандыр.

Алар иҗаты белән бер танышсаң, әсәрләрдән алынган тәэсир озак саклана. Чөнки бу иҗат җимешләренә бары тик алар гына, хатын-кызлар кулы гына тудыра ала торган сыйфатлар хас.

Рада Нигъмәтуллина, мәсәлән, хатын-кызларыбыздан бердәнбер скульптор буларак, балаларга мәхәббт темасын үзенчәлекле ача. Соңгы вакытта ул жанрлы скульптура композицияләрен иҗат итү белән мавыкты. Һәр әсәрнең үзәгендә — хатын-кыз яки бала образы.

Елизавета КИСЕЛЕВА. «Университет — Казанның горурлыгы» (плакат).





Раушан **ЯКУПОВА.** «Кызыл чәйнекле натюрморт».

Матурлык дөньясында

Раушан Якупова — натюрмортлар остасы. Рәссамның бу өлкәдә үзе яраткан темасы бар: тулып пешкән алмалар, күгелҗем сливалар, авыздан сулар китерә торган йөзем җимешләре... Үзенең «Алмалар» һәм «Кызыл чәйнекле натюрморт» әсәрләрендә ул бу әйберләрнең, җимешләрнең кабатланмас матурлыгын ачып сала.


Елизавета Киселева төрле жанрларда иҗат итә. Аңа плакатлар да, графика да, хәтта монументаль әсәрләр дә чит түгел. Рәсем сәнгатенең кайсы өлкәсендә эшләсә дә, Елизавета Киселеваның иҗат алымы әллә кайдан аерылып тора. Аның плакатлары ачык төсләргә бай, эчтәлекләре һәркемгә аңлаешлы.

Гайшә Рахманкулова иҗаты хакында күбрәк сөйлисе килә. Ул — рәсем сәнгатенә килгән татар кызлары арасында беренче кеше. Гайшә ханым акварель белән эш итә. Аңа бу техниканың иң тирәндә яткан серләре таныш. Рахманкулова иҗат иткән натюрмортлар, табигать күренешен сурәтләгән рәсемнәр төсләрнең гаҗәеп бәйләнешен тудырган. «Казан бүләкләре» натюрмортын алыйк. Монда без көндәлек тормышыбызны чолгап торган матурлыкларның җыелмасын күрәбез: Казан сөлгесе, агач кашыклар, сыбызгылар, әче бал кисмәге... Барысы да — халык арасында киң таралган, көндәлек кулланылышта йөри торган гади әйберләр. Нинди нәфисләр алар!

Рәссам кайчак төсләрнең иң ачыкларын сайлый, гүя бөтен тирә-юньне бизәргә омтыла. Кайчак исә Гайшә Рахманкулованың буяулары «тынычланып» кала, кабатланмас серле образ туа. Мәсәлән, «Көнчыгыш натюрморты»ндагы көмеш кувшин җемелдәве, келәм елкылдавы, чигелгән кәләпүш сурәте уйларны оста куллы борынгы һөнәрчеләр дөньясына алып китә.


Хатын-кыз рәссамнарыбыз иҗаты турында күпме генә сөйләсәк тә, әсәрләр үзләре тудырган кадәр ләззәтне татыту мөмкин түгел. Шуңа күрә укучыларга киңәш бирәсе килә: мөмкинлек чыкканда, күргәзмәләргә рәхим итегез, дуслар! Сезне рәсем сәнгатенең серле дөньясы көтә!

Вера ЦОЙ,
Татарстан рәсем сәнгате музееның бүлек мөдире.



Елизавета **КИСЕЛЕВА.** «Партия — безнең эпохабызның акылы, намусы һәм вөҗданы» (плакат).


Гайшә **РАХМАНКУЛОВА.** «Көнчыгыш натюрморты».





Гайшә **РАХМАНКУЛОВА.** «Казанның истәлекле бүләкләре».

ХИКӘЯ



Ж

ирән чәчле дүрт яшьлек малай ул. Өйдә алар күп вакыт карт әбисе белән икәү генә яшиләр. Югыйсә, әти-әнисе дә, дәү әнисе белән дәү әтисе дә бар Юрандның. Аларны малай айга-елга бер генә күрә. Карт әбисен ул «картыйсы» дип йөртә, чөнки өйдәге бөтен кеше аңа шулай дәшә. Картыйсыннан Юранд минут та калмый, бер мендәрдә йоклыйлар, бер кашыктан ашыйлар диярлек. Кибеткә ипи-сөт алырга да бергә баралар, сумканы да бергә күтәреп кайталар, бишенче катка менгәндә дә малай кулын сумкадан ычкындырмый. Бер, ике, өч... Ун баскыч күтәрелгәч, мәйданчыкта туктап ял итәләр, рәшәткәле тәрәзәдән тышка карап торалар.

— Картыйсы, күл буена чәчәк җыярга кайчан барабыз?

— Кар өстендә чәчәк үсми бит, улыкаем.

Юранд моны белә, зәңгәр-сары чәчәкләрне сагынып кына әйтүе. Һавада бөтерелгән кар-чәчәкләрне бераз күзәткәч, югарыга күтәрелү дәвам итә: унбер, унике, унөч...

— Җитмеш тугыз! Менеп тә җиттек, — ди Юранд, картыйсы артыннан кабатлап. Өйгә кереп, өс киемнәрен салгач, чәй эчәргә әзерлек башлана. Яшел чәйнек кайнап чыккан арада картыйсы көмәч кисә, өстәлгә ике пар чынаяк куя. Аннары чәчәкле тәтәй чәйнекнең иске чәен түгеп, аны ак чүпрәк белән ялтыратканчы сөртә. Өстәл башындагы биек урындыкка утырган Юранд, чәй савытын кулына алып, картыйсына әзерләп тора. Бу нәни сандык Юрандка бик ошый. Сандыкның капкачы ике кат: өскесе кызыл-зәңгәр бизәкле, аскысы бизәксез, ялтырап тора. Юранд бармагы сыярлык бәләкәй дүңгәләкне тартса, капкач «челт» итеп ачыла. Ә сандыкта, кипкән лимон кабыклары арасында, хуш исле чәй. Тәти чәйнекнең борын тирәсендәге, авыз читендәге чәй сарылары сөртелеп бетүгә, Юранд нәни сандыкны ачып җибәрә. Картыйсы чәйнеккә бер балкалак чәй сала, калак очына әлдереп шикәр комы сибә. Аннары шүрлектәге үтә күренмәле каптан ике төрле яфрак алып сала да, шулар өстенә гөбердәп кайнап торган су агыза. Урман-болыннарның хуш исен эченә алган чәчәкле чәйнек ак сөлге белән ябыла. Картыйсы көмәчкә май ягып, Юранд алдына куя.

— Картыйсы, чәйгә җиләк яфрагы салдыңмы?

— Салдым, бөтнек яфрагын да онытмадым.

— Чәеңне бик куе ясама, картыйсы, йөзең саргаеп китте бугай.

— Минем йөз саргаясын саргайган инде, улым, менә синең чәч кызара бит әле, әтиеңә ничек җавап бирербез?

Юранд шундук чәчен сыйпап ала, картыйсы белән ышерен сүз берләшкән сыман мут кына көлеп куя. Ә картыйсы сөйләнә-сөйләнә онысын сыйлый:

— Минем улым сөт эчә шул ул, шуңа аның йөзе шикәр кебек ак. Чәйне дә сөтләп эчә ул.

Сажидә СӨЛӘЙМАНОВА


ЮРАНД

Картыйсы малайга улым дип дәшә, исемен әйтергә туры килгәндә дә соңгы авазын төшереп калдыра, Юран ди. Гомумән, бу исем шактый күп сүзләргә сәбәп булды. Андый исем юк дип, загса малайны язмый интектергәннәр иде. Кайбер ата-аналарның беллексезлеге аркасында, загс эшчеләренә гаять күп мәшәкать туа икән. Үсеп җиткәч, балалар, «миңа мондый исем кирәкми» дип, гариза тотып киләләр, ди. Шулай, Рафинат дигән малайның исемен Рәфкать дип алыштырганнар, Фикус исемлесен — Фәез дип. Ә болар терәлеп үз сүзләрендә торалар икән. Әти кеше экспедициядә йөргәндә бер поляк егете белән дуслашкан, дуслык хөрмәтенә аның исемен улына куштырасы килә икән. «Син дә шул исемне яклыйсыңмы?» — дип, әнисеннән сораганнар. «Әтисе ничек тели, шулай кушсын, аның малае», — ди икән әнисе.

Әнә шулай бик еракташ, чит илдән килгән Юрандның исеме. Исемне кушып, малайны картыйларына калдырып, геологлар отыры ераккарак китеп бардылар.

Кай көннәрдә картыйсының башы сызлый, ул диванга ятып тора. Аның көндез сузылып ятканын бер дә генә сөйми Юранд.

— Сырхап торам әле, улым.



Рада НИГЪМӘТУЛЛИНА. «Беренче класс балалары».

— Сырхап торма, тиз генә тор, тор инде, картыйсы, сырхап торма...

Һәрвакыт шулай: картыйсына авырырга мөмкинлек юк, сабыйның күңелен төшермәс өчен ул, сызлаган башын диван аркасына сөяп, дисбе тарта-тарта, иренен кыймылдатып утыра. Шулай яхшырак та: ятсаң, гел ятуга китә. Юранд та аягын бөкләп, картыйсы каршына җайлап урнаша.

— Дәү әни белән дәү әти кайчан кайта?

— Тиздән кайтып җитәрләр инде, улым.

— Кайда соң алар?

— Гәстрүлдә.

— Анда нишлиләр?

— Эспитәкел уйныйлар.

— «Спек-та-кль» диген!

Картыйсын шулай дөрес сөйләшергә өйрәтә малай. Ифрат кызгана картыйсын Юранд, чөнки аның бик еш башы сызлый. Шуңа да малай картыйсы белән өйдә кала. Югыйсә, дәү әниләре аны үзләре белән спектакль уйнарга алып китәселәр иде. Ул инде бер спектакльдә уйнады һәм зур уңыш казанды. Клубка баргач, башта Юранд картыйсы белән карлыгач оясы сыман биек урыннан сәхнәгә карап утырды. Сәхнәдә дәү әнисе белән дәү әтисе сөйләшеп, көлешеп, эшләп йөрделәр. Аннан кайдадыр сугыш башланды, абыйлар сугышка китте. Дәү әтисе дә китте. Картыйсы мышык-мышык килеп, кульяулык белән күзен, борынын сөртә. Шулай елый ул. Юранд сәхнәдәге вакыйгаларның очын югалтты, аңа картыйсы кызганыч. Шулай утырган арада, бер таныш апа: «Дәү әниең чакыра», — дип, Юрандны алып китте, картыйсы калды. Озын кара күлмәк кигән, җилфердәп торган кара шарф бөркәнгән, озынаеп һәм нечкәреп киткән дәү әнисе оныгын җитәкләп алды.

— Без синең белән кулга кул тотынып, ә-әнә теге ишек ягына китәбез, — диде ул, Юрандның колагына иелеп.

— Сугышка китәбез, әйе?

— Юк, сугыш бетте инде.

— Ә кая барабыз?

— Дәү әтиең янына.

— Ул бит сугышка китте.

— Кайтты инде ул.

— Ә тагын барамы?

— Юк, хәзер сугыш булмый. Эндәшмә, монда сөйләшергә ярамый.

Юранд сак кына әйләнә-тирәгә карап алды. Ят кешеләр сөйләшми генә йөренеп торалар. Өстән, әллә нинди караңгы күктән юан-юан баулар асылынып төшкән. Менә бер заман музыка яңгырады, нидер шылдырдады, гөжләде, җил исеп куйды. Нәрсәдер кубып, ачылып китте.

— Як-ягыңа каранма, миңа тотынып кына бар, — дип пышылдады дәү әнисе Юрандның колагына. Һәм алар, икесе җитәкләшеп, биек күпер аша каядыр киттеләр. Музыка уйный, бер апа өзек-өзек итеп нидер сөйли. Бераздан бөтен нәрсә тынып кала. Менә инде дәү әнисе бая күрсәткән ишеккә дә җитәләр. Озын яшел пәрдәләр аралыгына керер алдыннан малай серле булып тоелган караңгырак якка борылып карыйсы итте. Аннан бик күп күзләр Юрандка төбәлгәннәр. Юрандның каравы булды, кешеләр кулларын чәбәкли башладылар. Дәү әнисе ачуланмыймы дип, Юранд тиз генә аның йөзенә үрелеп карады. Ачуланмады дәү әнисе, Юрандның кулын ныграк кысты, хәтта яратып елмайды. Кешеләр гөжләшеп кул чабып калды, ана белән бала, салмак кына атлап, сәхнәдән чыгып киттеләр. Каршыларында теге таныш апа басып тора иде, дәү әнисе Юрандны кочаклап үпте дә аңа тапшырды, үзе әле генә чыккан ишектән кире кереп югалды. Соңыннан кечкенә бүлмәдә Юрандны бик күп апалар кочакладылар, үпте, абыйлар шапылдатып кулларын бирделәр, дәү әтисе күтәреп үк алды. Болар бар да сугыштан кайтканнар, дип уйлады Юранд, алар белән бергә сөенде.

Өйгә кайткач, картыйсы нигәдер елады да елады.

— Сабыйның күңеленә җәрәхәт ясыйсың, тукта инде, әнкәй,— дип өзгәләнде дәү әнисе. Картыйсы аның саен:

— И кызым, безнең турыда язганнар бит моны, исемнәребезне генә үзгәрткәннәр, и килен...— дип яшь койды. Бу кадәресен Юранд аңлый алмый. Аңласа, картыйсына ягымлы сүзләр әйтер, аны тынычландырыр, болайрак дип сөйләр иде бәлки: «Бик еракта яшәүче кыргыз язучысы безне белми, ул бүтән картый турында язган, бөтен аналарга уртак хәсрәт китергән заман турында язган ул...»

Юранд әле кечкенә, алай сөйли дә, алай уйлый да белми. Әмма картыйсын ялгыз калдырып беркая китми, боеккан чакларында юата:

— Хәзер сугыш булмый, елама.

Январь, 1977 ел.

Дәрҗия Аппакованың тууына 80 ел

ДУСЛЫК-ТУГАНЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

Аның тормышы бик зур үзгәрешләр һәм үсеш чорына туры килде. Аның гомер юлы илебезнең төрле өлкәләреннән, төрле милләт халыклары арасыннан үтте.

Шуның өстенә табигать аның күзләренә сизгерлек, акылына зирәклек, бар күргән-кичергәннәрен мавыктыргыч итеп кешеләргә сөйләрлек талант биргән иде.

Бу кеше — Дәрҗия Аппакова.

Ул 1898 елның мартында элекке Минзәлә өязендә ярлы крестьян гаиләсендә туган, унөч яшендә Казанга килеп, учительская школага укырга кергән. Укуын тәмамлагач, аны Казандагы үрнәк мәктәптә укытучы итеп калдыралар.

Октябрь революциясеннән соң ул, үз авыл халкын агарту теләге белән, туган ягына кайта. Укыта һәм газеталарга мәкаләләр язышa. 1922 нче елда яңадан Казанга килеп, Зур драма театры каршындагы театр студиясенә укырга керә. Аны тәмамлагач, артистка була. Аннан соң комсомолның өлкә комитетында инструктор булып эшли, соңрак Бөгелмә кантонында хатын-кызлар арасында эшли. 1928 елдан алып Ташкентта укытучы була, Урта Азиядә хатын-кызлар арасында зур эш алып бара.

Язучының беренче зур әсәре — «Кечкенә Бануның тарихы» исемле повесте — укучылар тарафыннан бик яратып кабул ителде һәм рус, үзбәк, инглиз телләрендә дә басылып чыкты.

Бу әсәрдә җирсез крестьян кызы Бануның балачактагы авыр тормышы һәм аның рухи яктан үсеп, чыныгып, азатлык һәм якты тормыш өчен көрәш юлына аяк басуы мавыктыргыч итеп сурәтләнә.

Дәрҗия Аппакова үзенең талантын, башлыча, хатын-кызлар һәм балалар тормышын тасвирлауга багышлады, аның әсәрләрендә төрле милләт кешеләренең бик матур образлары күз алдына килеп баса. «Мәмәт һәм карт Амон» повестенда төркмән балаларының революциягә кадәрге чордагы авыр тормышы чагыла, «Люли» повесте чегән балаларының язмышына багышланган.


(1898—1947)

Дәрҗия Аппакованың «Михнәт» дигән романында коллективлашу чорында Үзбәкстанда барган каты сыйнфый көрәшнең киң, катлаулы картинасы ачыла. «Сәнәкчеләр» повесте да катлаулы язмышларны эченә ала, ярлы кызы, укытучы Фатыйма образы аның үзәгендә тора.

Дәрҗия Аппакова — күп сәхнәләрдә зур уңыш белән барган, балалар өчен язылган пьесаларның авторы. Аның «Тапкыр егет», «Шүрәле», «Бишек җыры», «Камыр Батыр» һәм башка әсәрләрен бүгенге көндә дә балалар рәхәтләнеп уйныйлар һәм ләззәтләнеп карыйлар.

Халкыбызның талантлы, олы җанлы кызы Дәрҗия Аппакова иҗат иткән әсәрләр әдәби хәзинәбездә бүген дә лаеклы урын алып тора.

ИТАЛИЯ ТУРЫНДА ӘКИЯТЛӘР

Аналар турында сөйләрдәй сүзнең очы-кырые юк.

Шәһәр инде атналар буе тимер кием-ле дошманнар тарафыннан тыгыз бөҗра эченә уратылган хәлдә иде; төнлә учаклар ягыла һәм аларның уты куе караңгылык эченнән шәһәр коймаларына әллә ничаклы кызыл күзләр карагансыман күренә. Алар, кеше кайгысына сөенгәндәй, дөрләп яналар һәм аларның шулай сагалап януы камалган шәһәр эчендә караңгы уйлар тудыра.

Койма өстендәгеләр дошман әлмәгенең торган саен тыгызлана баруын һәм аларның кара күләгәләре учаклар тирәсендә әрле-бирле йөрүләрен күрәләр; тук атларның кешнәүләре ишетелә, кораллар чыңлый, шаркылдап көлгән тавышлар һәм үзләренең җиңүләренә ышанган кешеләрнең шат җырлары яңгырый — ә дошманның җырын һәм көлүен ишетүдән дә йөрәк әрнеткечрәк нәрсә бар?

Шәһәргә су килә торган барлык инешләрне дошманнар мәетләр белән тутырганнар, алар, шәһәр коймасы әйләнәсендәге йөзем куакларын яндырып, кырларны таптап, бакчаларның агачларын кискәннәр — шәһәрнең бар ягы да ачык һәм аның өстенә көн саен диярлек дошман туплары, мушкетлары чуен һәм кургашын яудыра.

Шәһәрнең тар урамнарыннан, күңелсез генә атлап, сугыш белән йончыган, ачлы-туклы солдатлар үтә; өйләрнең тәрәзәләреннән яралыларның ыңгырашуы, саташып кычкыруы, хатын-кызларның дога укуы һәм балалар елашуы ишетелә. Кешеләр акрын гына, боек сөйләшәләр һәм сөйләшкән чакта, кинәт бер-берсенең сүзен бүлдереп, дошман һөҗүм итмиме икән дип, игътибар белән колак салып тыңлыйлар.

Кич җитү белән тормыш бигрәк тә авырлаша, ул чагында инде ыңгырашулар, елаулар тынлыкта аермачыграк ишетелә һәм, алар ишәяләр, ерактагы тау тарлавыкларыннан күгелҗем кара күләгәләр үрмәләп чыгалар һәм, дошман лагерен ышыклап, ярым җимерек коймаларга юнәләләр, ә караеп очлайган таулар өстендә, кылыч белән яньчелеп беткән һәм юкарган калкандай, ай калкып чыга.

Эштән, ачлыктан йончыган кешеләр ярдәм көтми, көннән-көн өметләрен җуя барып, ул айга, очлы тау башларына, кара тарлавык куышларына һәм дошманнарның шау-шулы лагерена куркып карыйлар — аларга бөтенесе үлемне хәтерләтә һәм бер генә йолдыз да аларны юатырлык булып балкымый.

Өйләрдә ут яндырырга куркалар, урамнарны куе караңгылык баса һәм шул караңгылыкта башыннан ук кара плащка төренгән бер хатын, тирән су төбендәге балыктай, тавыш-тынсыз күзгә чалынып үтә.

Аны күргәч, кешеләр бер-берсеннән:

— Шулмы бу? — дип сорыйлар.

— Шул.

Һәм капка асларындагы куышка качалар яисә, башларын аска иеп, дәшми-тынмый аның яныннан йөгереп үтәләр, патруль башлыклары исә кырыс тавыш белән аны кисәтәләр:

— Тагын урамга чыктыгызмы, донна Марианна? Карагыз аны, үтерүләре мөмкин, һәм гаепләне берәү дә эзләп йөрмәс...

Хатын гәүдәсен турайта, көтә, ләкин патруль, аңа кул күтәрергә кыймыйчамы, әллә җирәнепме, үтеп китә; кораллы кешеләр, үлек яныннан үткәнсыман, аны читләтеп үтәләр, ә ул караңгыда кала һәм шәһәрнең бәхетсезлекләрен үзендә гәүдәләндергәндәй, карадан киенгән һәм телсез ул хатын тагын берүзе акрын гына урамнан борыла-борыла каядыр бара, — ә тирә-юньдә кайгылы авазлар: ыңгырашу, елау-сыктау, дога укулар, җиңүдән өмет өзгән солдатларның боек сөйләшүләре аны эзәрлекләп, артыннан үрмәләп баралар.

Ул гражданка да, ана да. Ул туган иле турында да, улы турында да уйлый: аның улы, шат күңелле һәм каты бәгырьле чибәр егет, шәһәрне җимерүче кешеләргә баш булып тора; ана күптән түгел генә улына горурланып карый, аны Ватанына биргән иң кыйммәтле бүләге итеп, үзе шул шәһәрнең кешеләренә ярдәм итсен өчен тудырган рәхимле көч итеп карый иде әле, ә шәһәр — аның үзе туган, улын табып, имезеп үстергән оясы иде. Бабалары салган йортларның, бабалары койган шәһәр коймаларының борынгы ташлары, кан кардәшләренең сөяге күмелгән җир, кешеләрнең өметләре, легендалар, җырлар — болар бөтенесе аның йөрәгенә йөзләрчә өзелмәс җепләр белән бәйләнгән. Хәзер ул йөрәк иң якын кешесен җуеп, елый: ул үлчәү шикелле, ләкин шунда үзенең улына һәм шәһәргә булган мәхәббәтен салып үлчәгән чакта, Марианна аларның кайсы авыррак, кайсы җиңелрәк икәнен аңлый алмый.

Ул шулай төннәр буе урамда йөри, һәм күбесе аны танымыйча, куркалар, аның кара сыны барысының да янында гына торган әҗәл булып гәүдәләнә, ә танысалар — хыянәтченең анасы яныннан дәшми-тынмый үтеп китәләр иде.

Ләкин бер тапкыр ул шәһәр коймасы буендагы аулак почмакта икенче бер хатынны күрде: ул хатын, бер үлек янына тезләнеп, хәсрәтле йөзен йолдызларга текәгән хәлдә, тораташтай хәрәкәтсез, гыйбадәт кылып утыра, ә койма өстендә акрын гына сакчылар сөйләшә, койма ташына тиеп киткән корал чыкырдап куя иде.

Хыянәтченең анасы:

— Ирецме? — дип сорады.

— Юк.

— Энеңме?

— Улым. Иремне моннан унөч көн элек үтерделәр, монысын — бүген.

Һәм үлгән егетнең анасы, тезләнеп утырган җиреннән торып, карусыз тавыш белән:

— Мадонна бөтенесен күрә, бөтенесен белә, рәхмәт яусын үзенә,— диде.

Беренче хатын:

— Ни өчен? — дип сорагач, тегесе аңа җавап бирде:

— Хәзер, улым ил өчен сугышып намус белән үлгәннән соң әйтә алам: мин аның өчен куркып йөрдем. Ул җилбәзәк малай күңелле тормышны бик ярата иде, шуңа кызыгып, шәһәргә хыянәт итмәгәе, дип курыккан идем. Әнә Марианнаның улы, безнең дошманнарның башлыгы, ходай һәм кеше дошманы, шулай итте ич. Ләгънәт төшсен аңа һәм ул яткан ана карынына!..

Марианна, битен каплап, аның яныннан китте һәм, икенче көнне иртә белән шәһәрне саклаучылар янына барып:

— Улым сезгә дошман булган өчен яисә мине үтерегез, яисә капканы ачыгыз да, мин аның янына китим... — диде.

Алар аңа:

— Син — кеше бит, сиңа туган ил кадерле булырга тиеш; синең улың, безнең һәркайсыбызның дошманы булган кебек, синең өчен дә дошман булырга тиеш, — дип җавап бирделәр.

— Мин ана, мин аны яратам. Аның шундый булып китүенә үземне гаепле саныйм.

Шуннан алар, бу хатынны нишләтергә икән дип, үзара киңәшләшкәннән соң, шундый бер карарга килделәр.

— Намус белән эш иткәндә, без сине улыңның гөнаһсы өчен үтерә алмыйбыз, синең аны шундый коточкыч гөнаһ эшләргә котыртуың мөмкин түгел, без моны беләбез һәм синең ни дәрәҗәдә газаплануыңны сизенәбез. Ләкин синең шәһәргә заложница буларак та кирәгең юк — улың синең турыдаваемланмый, ул, иблис, сине онытkандыр. Үзеңне җәзага лаеклы санасаң, менә сиңа җәза. Безгә калса, үлемнән куркынычрак бу!

— Әйе, — диде ана. — Бу куркынычрак.

Алар, аның алдында капканы ачып, аны шәһәрдән чыгарып җибәрделәр һәм аның улы түккән кан белән лач булган туган җир өстеннән баруын койма өстеннән карап тордылар: ул, аякларын җирдән көч-хәл белән куптарып алып, шәһәрне саклаучыларның үле гәүдәләренә башын ия-ия, акрын гына барды, аяк астындагы сынган коралларны җирәнгән кыяфәт белән читкә тибәргәләде — аналар һөҗүм коралына нәфрәт белән карыйлар, алар тереклекне саклаучы коралны гына таныйлар.

Ул, гүя плащ астындагы кулына ниндидер сыек нәрсә белән тулы чынаяк тотып, шуны чайпалдырып түкмәгәем дип курыккан сыман бара иде. Ул ераклашкан саен кечерәя барды, ә койма башыннан карап торучыларга үзләренең боегулары да, өметсезлекләре дә шуның белән бергә ияреп киткәндәй тоелды.

Алар аның ярты юлга җиткәч туктавын һәм, плащының башлыгын артка тибәреп, озаклап шәһәргә карап торуын күрделәр, ә анда, дошман лагеренда, аның ялгызы гына кыр уртасында басып торуын күреп алдылар, һәм шул хатын төсле үк кара сыннар, ашыкмыйча, сакланып кына аңа таба килә башладылар.

Килеп җиткәч, аның кем икәнен, кая баруын сорадылар.

— Сезнең башлыгыгыз — минем улым, — диде ул, һәм солдатларның берсе дә аның шулай булуына шикләнмәде... Алар, аның улының акыллылыгын, батырлыгын мактый-мактый, янәшә бардылар, хатын аларның сүзләрен тыңлаганда, горурланып, башын күтәреп барды һәм гаҗәпләнмәде — аның улы шундый булырга да тиеш!

Һәм менә ул хәзер үзе аны дөньяга килүеннән тугыз ай элек үк белгән кешесе каршында, һәрвакыт үзенең йөрәгендә итеп сизгән кешесе каршында тора, ул кеше ефәк һәм хәтфә кием-

нәр кигән һәм аның коралы да асылташлар белән бизәлгән. Бу шулай булырга да тиеш иде, анасы төшендә дә аны әллә ничә тапкыр нәкъ әнә шундый бай, атаклы, сөекле итеп күргән иде.

— Әни! — диде ул, анасының кулларын үбеп.— Син минем янымә килгәнсең, димәк, син мине аңлагансың. Иртәгә үк мин ул каһәр суккан шәһәрне алам!

Анасы:

— Үзең туган шәһәрне,— дип аның исенә төшереп куйды.

Үзенең күрсәткән батырлыкларыннан исергән һәм тагын да зуррак данга сусап шашкан улы аңа яшьләрчә масаеп, дәртләнеп сөйләде:

— Мин дөньяда һәм дөнья өчен туганмын, аны гаҗәпләндереп шаккатырыр өчен туганмын! Мин ул шәһәрне синең хакка гына аяп тордым, ул, минем аякка кадалган шырпы төсле, миңа дан казану юлында үзем теләгән тизлек белән барырга комачаулап тора. Ләкин хәзер — иртәгә үк — мин ул кире беткәннәрнең оясын җимерәм!

— Андагы һәрбер таш синең бала чагыңны белә һәм хәтерли,— диде ана.

— Кеше сөйләттермәсә, ташлар — телсез алар, таулар телгә килеп минем турыда сөйли башласыннар, мин менә шуны телим!

— Ләкин — кешеләр? — дип сорады анасы.

— Әйе, алар хәтеремдә, әни! Миңа алар да кирәк, чөнки геройлар кешеләр хәтерендә генә үлми сакланалар!

Ана:

— Герой — үлемгә каршы тереклек иҗат итүче, үлемне җиңүче кеше була ул...— диде.

— Юк! Җимерүче кеше дә шәһәрләр салучы төсле үк данлыклы. Менә кара — Римны Эней салганмы, әллә Ромул салганмы, без анысын белмибез, ә менә ул шәһәрне җимерүче Аларихның һәм бүтән геройларның исеме анык билгеле...

Ана:

— Ә шәһәр алар барысы да үлеп беткәннән соң да яши...— дип, аның исенә төшереп куйды.

Егет кояш баеганчы анасы белән шулай сөйләште; анасы аның акылсыз сүзләрен торган саен сирәгрәк бүлдерде һәм аның мәгърур башы торган саен түбәнрәк иелә барды.

Ана — иҗат итә, ул — саклый һәм аның алдында җимерү турында сөйләү — аңа каршы сөйләү булып чыга, ә егет моны белми иде һәм анасының яшәвенең мәгънәсен юкка чыгарды.

Ана — һәрвакыт үлемгә каршы. Аналар кеше яшәгән өйгә үлем алып керүче кулны дошман күрәләр,— данның йөрәк үтергеч суык ялтыравыннан күзе камашканга, аның улы шуны күрмәде.

Әш үзе иҗат иткән һәм саклаган тереклеккә кагылган чакта ананың ни дәрәҗәдә батыр, ни дәрәҗәдә акыллы һәм рәхимсез җәнлек икәнен дә белми иде ул егет.

Ана бөгелеп утырган иде һәм аңа башлыкның кыйммәтле чатыры авызыннан шәһәр күренеп торды. Марианна хәзер җимерергә теләүче баласының аны рәхәт сискәндереп карынында яралуын беренче тапкыр шул шәһәрдә татыган, ул баланы тудыру газабын да шунда кичергән иде.

Кояшның кызыл нурлары шәһәр коймаларын һәм манараларын кан белән коендыралар, тәрәзә пыялалары дәһшәтле булып елтырый, гүя бөтен шәһәр яраланган кебек һәм йөзләрчә яралардан кызыл сул, тереклек суле аккан кебек тоела иде; вакыт үтте, һәм менә шәһәр үлексыман карая башлады һәм аның өстендә, җеназа шәмнәредәй булып, йолдызлар кабынды.

Ана анда, дошман күзе төшмәсен дип, ут кабызырга курыккан караңгы өйләрдәге үлем көтүче, шыпырт кына сөйләшкән төшенке тавышлы кешеләрнең, үлек исе тулы караңгы урамнардагыларның бөтенесен, барысын күрә; аңа якын һәм таныш алар; бөтенесе каршыда гына, дәшми-тынмый, аның карарын көтеп торалар, һәм ул үзен шул шәһәрдәге барлык кешенең дә анасы итеп сизә иде.

Кара тау башларыннан үзәнгә болытлар төштеләр һәм алар канатлы атларга охшап, үлемгә хөкем ителгән шәһәр өстенә агылдылар.

— Төн бик караңгы булса, бәлки без аңа төнлә үк һөҗүм итәрбез,— диде Марианнаның улы һәм кылычын караштыргалап өстәп куйды: — Күзгә кояш төшеп, коралның ялтыравы күзне камаштырган чакта үтерү җайсыз, андый вакытта күбесенчә туры сугып булмый.

Анасы аңа дәште:

— Кил әле, башыңны күкрәгемә куеп бала вакытыңда нинди яхшы, шат күңелле булуыңны, бар кешенең дә сине яратканын исеңә төшерә-төшерә ял ит.

Ул карышмады, анасының тезенә ятты һәм:



— Мин бары тик данны сөям һәм мине шундый итеп тудыруың өчен сине сөям,— дип, күзләрен йомды.

Анасы, аның өстенә иелеп, сорау бирде:

— Ә хатын-кызлар?

— Алар — бик күп, артык татлы әйбер ничек булса, алар да шулай тиз туйдыра.

Ана соңгы тапкыр:

— Син балаларың булуын да теләмисеңме? — дип сорады.

— Нигә кирәк алар? Үтерер өченме? Минем ише берәрсе аларны үтерер, ә минем йөрәгем әрнер, ул вакытта мин инде картайган булырмын, алар өчен үч алырдай көчем калмас.

— Син матур, ләкин яшен кук игелексез,— диде анасы, көрсенеп.

Улы елмаеп җавап бирде:

— Әйе шул, яшен кук...

Һәм, сабыйдай, анасының күкрәгендә йокыга талды.

Ана шунда аның өстенә үзенең плащын япты да йөрәгенә пычак кадады, егет сискәнеп, шунда ук үлде — улының йөрәге кайда тибүен яхшы белә иде шул ана. Һәм аның үле гәүдәсен үзенең тезе өстеннән шунда таң калып торган сакчылар аяк астына ташлады да шәһәр ягына карап әйтте:

— Кеше буларак — мин илем өчен кулымнан килгәннең бөтенесен эшләдем; ана буларак — мин улым янында калам! Миңа бүтән бала тудырырга соң инде, минем яшәвемнең берәүгә дә кирәге юк.

Һәм әле улының кан җылысы — аның үз канының җылысы суынырга да өлгереп җитмәгән пычакны бер дә икеләнмичә үз күкрәгенә кадады һәм бу юлы да туп-туры йөрәккә чәнечте — йөрәк әрнегән чакта аңа туры кадау авыр түгел.



Әмир ФАТЫЙХОВ.

Башкортстан, Яңавыл поселогы.

ОЧЕРК

Яшьлек җыры

Рәшит СӘФИУЛЛИН рәсеме

Шәмсекамәр әбинең, гадәтенчә, тавыкларга җим сибеп йөргән чагы иде. Әнә шундый иртәнге сәгатьләрдә алар капкасы төбенә милиция машинасы килеп туктады. Туктады да аннан берьюлы ике милиционер сикереп төште.

— Шәмсекамәр әби Шакирова сез буласызмы? — диде аларның берсе, ишегалдына да кереп җитмәстән.

— Мин булам.

— Сезне начальник чакыра.

Шулай диде һәм коштабагын тотып аптырап калган әбине машинага утырырга ашыктырды.

— Туктагыз әле, пожар сүндерергә түгелдер бит, ник болай ашыктырасыз, әллә балаларымның берәрсе берәр нәрсә эшләп ташлаганмы,— дип, Шәмсекамәр әби нигә икәнен белешмәкче иде, ләкин милиционер егетләр, элек әйткән сүзләрен кабатлап, ашыктыра бирделәр.

Менә ул, сигезенче дистәне куган Шәмсекамәр әби, милиция машинасына утырып, поселокның аргы ягыннан бирге ягына чыгып килә. Йөрмәгән юлы түгел. Ләкин ниндидер шик-шөбһә Шәмсекамәр әбине бөтен үткән тормышын тикшерергә мәҗбүр итә. «Өйдә генә яткан көемә нинди ярамаган нәрсә эшләдем икән соң?» — ди ул үз-үзенә һәм, җавап табалмыйча, тышны күзәтә. Ә машина Яңавыл поселогының саф Яңавыл өлешен артта калдырып, биек дамба өстеннән аның шәһәрчә өлешенә якынлаша. Шәмсекамәр әле Камәр генә булып, дөньяны яңа таный башлаган елларны, бил тиңентен сазламыкка кереп, иптәшләре белән шушында чәчәкләр җыярга, тәкыя үрергә, камыш өзәргә йөри торган иде.

Шуннан соң күп тә үтмәде, дөньясын астын өскә әйләндергән һәм бер уңайдан хәерче Шакир семьясын да землянкасыннан тартып чыгарган Октябрь килде. Менә дигән егеткә тормышка чыгып, без дә калай капкалы йортларда яшәрбез, дип хыяллана башлаган иде Шәмсекамәр. Тик үзләрен ялчы итеп тоткан Бохаров ишеләргә Октябрь ошамады. Чит ил байларын ярдәмгә чакырып, бөтен илгә каршы сугыш башладылар. Яңавыл бер аклар, бер кызыллар кулына күчеп торды.

Гражданнар сугышы бетеп, аның артыннан килгән аяусыз ачлык та җиңелеп, Шәмсекамәр инде күп балалы ана булгач, Яңавыл белән Иванай арасындагы ул тугайларда яңа заман кешеләре икешәр катлы йортлар күтәрә башлады. Стансага терәп салынган бу яңа авылны беренче елларда «Октябрь поселогы» дип йөрттеләр. Ә тора-бара ул район үзәгенә әверелде.

Кызыл путалы машина бер кызулап алды да кинәт туктап калды. Ике милиционер әбине култыклап җиргә төшерделәр, начальник каршына илтеп бастырдылар.

— Әбекәй, борчыганыбыз өчен, зинһар, гафу итә күр инде безнә. — Начальник кечелекле булырга тырыша иде. — Әнә атыбыз аягыннан язды, — дип әбигә һәйкәлдәй катып калган кара айгырны күрсәтте.

— Азинның туры юргасын дәвалаган шикелле сикертеп атлаган кара-туры айгырны Шәмсекамәр шундук танып алды. Хәлне аңлап, ул минуты-секунды белән болынга йөгерде, аннан төрле үләннәр җыеп кайтты, бер ишеләрен этисе эшләгәнчә чәйнектә кайнатып, яраны юды, кулы белән изеп икенчеләренең согын мамыкка сеңдерде һәм ярага бәйләде. Икенче атакага барганда кызыл командир яңадан үзенең сөйгән юртагында җилдерә иде.

Милиция бүлегенең кара айгыры әнә шул начдив юргасына охшый иде. Имгәнгән аягын күтәргән дә кешеләргә ялварып карый. Ветврач килеп, тубык сөягән марля белән урап, өч-дүрт көн атны урыныннан да кузгатмаска кушып киткән. Ләкин айгыр аннан соң да аягына басмаган. Шәмсекамәр әби шул марляны чиште дә иләп кенә әйтте:

— Моның имгәнүе монда түгел, оланнар, янбашы тайган моның, — диде һәм бер чиләк су белән сабын китерергә кушты. Йомышка киткән милиционер егет әйләнеп килгәнче, Шәмсекамәр әби атның арткы аякларын баганага тотып бәйләттерде, аннары үзе янбашы тирәсендә булышты һәм бераздан бауны чишәргә яравын әйтте:

— Йә, оланнар, ни булса булыр, алга таба тартып карагыз әле.

Кара кашка, авырткан аягын җиргә тидерер-тидермәс ике адым ясады да, иреннәре белән дәвалаучысының иңбашына кагылып, канәгать кешнәп куйды. Барысы да ни әйтергә белми тынып калдылар. Шәмсекамәр әбине алып килгән яшь милиционер, шул тынлыкны бозып, әллә нинди акцент белән:

— Әйттем пит... Так и есть. Әйшә-Патима кулы, — дип кычкырып җибәрде. Начальник кеше Шәмсекамәр әбигә рәхмәтләр укый, акча тәкъдим итә башлады. Чын күңелдән әйтелгән рәхмәтләрен әби сүзсез генә кабул итте, ә үзенә таба сузылган акчалы кулны күргәч, ул чын-чыннан ярсып-кабынып китте:

— Сез нәмә, тәртип сакчылары! Бу надан карчыкны Әмрикәдән алып килдек дисезме әллә?

кеше бит сез, безгә дә ярдәм итә алмассызмы дигән идек.

Шулай диде милиция начальнигы. Гомер буена йөрәк түрендә йөрткән кадерле исемне ишетү Шәмсекамәр әбине әллә нишләтеп җибәрде. Үзен алып килгән әлеге егетләргә үпкәсен дә оныттырды. Аның күзеннән яшьләр килде. Бер мизгелгә ул үзен янәдән унсигез яшьлек итеп, кызыл командир алдында басып торган, аның белән кара-каршы биеп йөргәндәй хис итте.

Гражданнар сугышының иң кызган чагы иде бу. Кыю командир үзе кебек үк курку белмәс солдатларын Бикбарды ягына һөҗүмгә алып китте. Менә ул үз исеме язылган көмеш кылычын ялтыратып (аны Казанны азат итүдә күрсәткән батырлыгы өчен Ленин үзе бүләк иткән дип сөйлиләр иде), иң алда бара. Рабакның теге ягында посып яткан колчакчылар көтмәгәндә ут ачып, бер пуля кызыл командирның атын бәреп екты. Начдив алга мәтәлеп төште, ләкин тукталып калмады. Алгы аягы җәрәхәтләнгән сөекле атын үзеннән артта килүче солдатка тоттырып, аны Яңавылга озатты һәм үзе акларны куып дәвам иттерде. Азин атын туры штабка, Бохаров бай йортына, ат караучы Шакирга алып килделәр, ләкин ул өйдә юк, җәяүле укчыларны фронтка алып киткән булып чыкты. Коноводның кем икәнен белмәсә дә, тышауланган

Бу минутта анық тайган буыннарны утыртучы түгел, ә таймаганнарын тайдыручы булып аласы килде. Шул эшкә әзерләнгәндәй ике кулы белән Америка ягына кизәнде:

— Анда гына ул кешенең яхшылыгы да, яманлыгы да акчага үлчәнә!

Шулай диде дә Шәмсекамәр әби капкага атлады. Начальник җәһәт кенә аның юлын кисте һәм, алдында баш иеп, янә гафу үтенде:

— Шәмсекамәр апа, тупаслыгым өчен, зинһар, гафу итә күр. Үпкәләтеп җибәрү — безнең эш түгел. Нинди зур бәладән коткардыгыз. Алып килдек, илтеп тә куярбыз. Берәр җиргә барасыгыз булса, безнең участковыйга гына әйтегез, шушы «Ветерок» сезнең карамакта булыр. — Сүземне әйтеп бетерми калмагаем дигәндәй, начальник сүзен ашыга-ашыга әйтте. Үзе сөйләде, үзе әлеге ике хезмәткәре белән Шәмсекамәр әбине кабинага кертеп утыртты һәм артыннан кул болгап озатып калды.


«Берәр җиргә бару» дигәне күп көттермәде. Урман ягында яшәүче кызының ишәеп ятуы турында хәбәр килде, һәм аны башка беркем түгел, ә участковый үзе китерде. Шәмсекамәр әби шушы хәбәрне тыңлаганда капка төбендә йомшак кына итеп ат кешнәп җибәрде, тәрәзәдән Бохар келәме җәелгән тарантас күренде.

— Һай, бу кадәр үк кирәкмәс ие лә, миңа атның гадирәге дә ярар ие. — Шәмсекамәр әби тарантаска утырырга кыймады. — Болай мин чын губернатор хатыны булып китәм түгелме соң?

— Вышерак ал, әби. Безнең өчен губернатор нәрсә ул? Теге әкият батыры Әйшә-Фатиманың үзе син. Югыйсә, техника заманында мондый канатлы атларда кем йөрер дисең. — Шулай дигән булды участковый, Шәмсекамәр әбигә утырырга ярдәм итеп, һәм шуның белән

аны әкияттәгедәй үзгәрешләр кичергән реаль җирлектән янә үткәннәргә алып китте.

— Менә бу төшкә күз сал, улым,— диде ул поселок кибете яныннан узганда. Яңавылның иң беренче кешесе шушында килеп йорт салган. Гражданнар сугышы вакытында кызылларның пушкалары шушында торды. Әнә теге йорт Нургуфаннар йорты, анда да штаб иде, без — өч кыз — шунда күрсәтмәләр алып, аклар



ягындагы авылларга «утырмага» чыгып китә идек. «Утырмага» дигәне аның болай гына, акларның кайда нинди этлекләр эшләвен, кайда ниләре булуын белеп кайта идек без. Тыңлаучы өчен бу гади тарих кына, укыса укыганы, тыңласа ишеткәне кадәр белә. Ә менә Шәмсекамәр әби өчен ул — аның үз тормышы. Совет власте өчен барган ике сугыш ясаган яраларны дәвалаган ул. Гражданнар сугышы вакытында атаклы Азин дивизиясе лазаретында шәфкать туташы булган, Бөек Ватан сугышыннан яраланып кайтучыларга бәялән бетергесез ярдәмнәр күрсәткән. Яралар белән бергә аның алдыннан бөтен ил тормышы үткән. Менә ни өчен ул бу гади үткәннәрне хикәяләп кенә үтә алмый. Һәр искә алуы саен баскан-йөрегән җиренә төбәлеп, озак-озаклап уйланып утыра. Утыра-утыра да тагын сөйләп китә:

— Яшь Совет республикасы өчен иң авыр чак булгандыр. Мурман ягыннан англичаннар, көньяктан Деникин белән Дутов килә диләр иде. Урал аръягыннан безгә Колчак килде. Кызыллар чигенә. Яңавылдан да китәләр. Азин дивизиясе штабы белән бергә татар театры йөри иде. Ул да ашыга-ашыга олауга төянә. Әнә шундый чакта һич көтмәгәндә Азин килеп чыкты. Атыннан сикереп төшеп, буркасын бер читкә атып бәрде дә, башындагы папахасын төзәтеп:

— А, ну, артисты! Озатучылар өчен концерт давай! — дип команда бирде. Насыйбулла Чикин гармун тартып җибәрде. Мәстүрә Апканаева биергә тотынды. Ул бер әйләнүгә каршысына Азин үзе сикереп чыкты. Стансада башланган ыгы-зыгыны күзәтеп, тагын акларга калабыз, дип елашу-куркышулар бетте дә куйды. Үзебез төшеп биергә тотындык.

Шунда Шәмсекамәр әби аягына тотынып куя. Милиционер егет, әллә урын уңайсызрак булдымы дип, аның урынын җайламакчы була. Моңа каршы әби:

— Урыным бик әйбәт, борчыласы юк, тик әнә шул Азинга, кызылларга булышып йөргәнсез дип, аклар аягыма атканнар иде. Шуннан калган кургашын кисәге хәзер әллә нишләп куя. Яшь чакта камчы белән ярулары да, атулары да берни түгел иде, ә менә картайгач...

Әйе, ул чактагы вакыйгалар Шәмсекамәр әбинең әле хәзер дә күз алдында. Кызыллар чигенеп, аклар килгәч, әтисе, энесе белән бергә, аны да 35 әр камчыга хөкем иткәннәр. Шәмсекамәргә чират җиткәч, акларның бер командиры кереп кычкырган:

— Туктатыгыз, чигенергә кирәк! — дигән.

Бишме-алтымы тапкыр гына сугып калганнар, ләкин чыгып барганда берсе аягына аткан...

«Ветерок» Бүә буе уйсулыкларыннан калкулыкка күтәрелә, тау артыннан тау калдырып, һаман саен югарыга алып менә. Түбәндә, елга буенда, Тат-Урады авылы, ә алар — районның иң биек ноктасында. Моннан бөтен тирә-юнь уч төбендәге кебек: артта Яңавылның күпкатлы йортлары, сулда — илдә иң арзан электр энергиясе җитештерүче Карман ГРЭСы. Аның биек-биек торбаларыннан диңгез булып җәйрәп яткан сусаклагыч өстенә ак тасмалар сузылган. Шәмсекамәр әби, ерак үткәннәрдән килгән уйларына бирелеп, җыр тыңлый:

Без яшь идек, баш имәдек,
Еласак та җырладык,
Окопларда һәм утларда
Туды яшьлек җырлары...

Җыр бер көчәеп, бер тынып, таулардан тауларга тарала. Аны Шәмсекамәр әбине кызы белән очраштырасы милиционер егет җырлый, ләкин Шәмсекамәр әбигә ул аерым бер кеше түгел, ә бөтен тирә-юнь, таулар, авыллар җырлый кебек тоела. Юк, алай гына да түгел, Шәмсекамәр әбинең якташлары Сәҗидә Сөләйманова белән Мәсгут Имашевлар тудырган бу җыр аның яшьлегенә багышланган һәм аны башка беркем түгел, ә шанлы чорлардан күп еллар аша бүгенге бәхетле көннәргә күчкән яшьлеге җырлый иде.

АЛСУ ГАЙНУЛЛИНА



„Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклендә (Т. Миңнуллин пьесасы) тамашачыны хәйран иткән бер күренеш бар: әле генә бүгенге көннең унҗиде яшьлек кызын уйнаган актриса борынгы заман туташына әйләнә дә куя. Вакыйга буларак, бу — искитәрлек хәл түгел. Сәхнә — шартлы урын, драматург белән режиссер теләгенә таянып, монда әллә нинди эшләр башкарылырга мөмкин. Тамашачыны мәсьәләнең икенче ягы шаккаттыра. Мең дә берне белүче, ачуы чыкса, егетеңне ник туганыңа үкендерә алучы бүгенге Гөлфирәне дә, борынгы заман туташы Йөзембикәне дә бер үк актриса уйный. Гөлфирә — сөйкемле, булдыклы, тәрбияле кыз. Аның холкында бабасының әтисе булган Әлмәндәр картның шуклыгы, тапкырлыгы, изге хәйләкәрлеге дә чагылып-чагылып китә. Унынчы дистәне ваклый башлаган Әлмәндәр, кызның кыланмышларына карап, үзенең яшьлеген, Йөзембикәгә гашыйк чакларын искә төшерә. Шул мизгелдә Гөлфирә — Алсу Йөзембикә — Алсуга әйләнә дә куя.

Карап утыручыга рәхәт. Артистларга исә мондый кискен борылышны кичерү, бер чордан икенчесенә сикереш ясау, әбисенең әнисе яшьлегендә яши башлау — гаять катлаулы хезмәт. Күпләр, мөгаен, моны башкара да алмас иде. Алсу Гайнуллина исә бу борылышка шундый ныклы әзерлек белән килә ки, тамашачы баштарак аның шул ук актриса икәнен абайламый тора. Өстенә чалбар кигән, күрше егете белән твист биегән Гөлфирәне бәби итәкле озын күлмәкле, яулыгын чөеп бәйләгән, чиләк-көянтә асып су буена төшкән борынгы заман Йөзембикәсе белән тиңләштерергә мөмкинме!! Бусы бит — бөтенләй башка дөнья кызы! Адымы да бер сөям генә, тавышы — күгәрчен гөлдерәве, кешеләргә күтәрелеп карарга да кыймый, бер кулы яулык читен әзерләп куйган: егет-җилкен очраса, йөзен хәзер каплап өлгерә. Бераздан, актрисаның осталыгы аркасында, тамашачы Йөзембикәнең икенче төрле сыйфатларын күрә башлый. Ул да, Гөлфирә кебек үк, хөр күңелле икән лабаса! Ул да бик күпне белергә тели, айның серлелеге аны уйга салган. Егетнең сүзләреннән әллә нинди мәгънәләр эзли. Йөзембикә Гөлфирәише генә дә булмас иде әле! Заманасы — теләкләргә тышау. Шулай да югалып калмаган ул, авылдагы йөзләгән кызның йөрәген яндыручы Әлмәндәрне үзенә гашыйк иткән. Җаен туры китереп, очрашу әмәлен дә эзләп тапкан — чишмәгә суга килгән. Су кирәк булган өчен түгел бит, һич юк, чиләгенә су алырга онытып кайтып ук бара әнә!..

Йөзембикә белән Әлмәндәрнең очрашуы тамашачының җанын тетрәтә, чөнки күрешү дигәнең туксан бер яшьлек картның хыялында гына фараз кылына бит, шайтан алгыры! Картның якасына котылгысыз әҗәл ябышкан, барысы белән дә хушлашыр сәгать суккан. Әлмәндәр гомеренең иң мөкатдәс мизгелләрен күз алдыннан кичерә: яшьлек! Йөзембикә! Гөлфирә! Гөлфирәсе — оныгының баласы, нәкъ Әлмәндәр картның яшьлек хыялы.

Сагыш аша нәтиҗә ясап куясың: гомере бушка үтмәгән бит моның, Әлмәндәр токымы яши бирә! Әсәрнең буеннан-буена килә торган шушы якты фикерне ачуга Әлмәндәр образы белән бергә Алсуның Гөлфирәсе дә, Йөзембикәсе дә зур өлеш кертә.

Алсу Гайнуллина — Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективына әле соңгы елларда гына килеп кушылды. Башкарган рольләре дә, катнашкан спектакльләре дә бармак белән санап чыгарлык. Әмма ләкин аның сәхнәдәге һәр чыгышы тамашачыга чын ләззәт, дөнья матурлыгын танытуда яңа ачкыч бирә икән, Алсу Гайнуллинаның театрга килүен сәнгатебездәге табышлардан санарга туры килә.

Аның сәхнәгә аяк басуы бары тик талантлы кешеләр язмышына гына хас булганча хәл ителә. Урта мәктәпне тәмамлап өлгермәс борын аны театр училищесына чакыралар.

БАЛАГЫЗ КИТАП

Балачактан ук китап укырга, аны яратырга өйрәнгән кеше гомере буе үзен бәхетле саный ала. Ул ялгыз түгел. Китап — аның киңәшчесе, ярдәмчесе, таянычы. Матур әдәбият кешенең холкы формалашуга уңай йогынты ясый, туры сүзле, кыю, гадел гражданин, ил өчен көрәшче әзерләүдә булыша. Академик В. А. Обручев, мәсәлән, Жюль Верн, Фенимор Купер, Майн Рид әсәрләре тәэсирендә генә сәяхәтче һәм табигать сөюче галим булуын телгә ала. Космонавт Юрий Гагарин Борис Полевойның „Чын кеше" повестен яратып укып, шул китап тәэсирендә очучылар арасына килеп керүен сөйли торган булган.

Балаларының бик инсафлы, укымышлы, эшлекле кеше булып өлгерүен теләүче әти-әниләргә минем шундый сорау бирәсем килә.

— Сез балагызны китап яратырга өйрәттегезме соң? Балагызның нинди китаплар укуы, ничек укуы белән кызыксынганыгыз бармы?

Беләм, соравыма каршы, гаҗәпләнеп сорау белән үк җавап кайтаручылар да очрар, мөгаен.

— Мәктәп нәрсә карый соң? — диючеләр бар ул, бар.— Матур әдәбият укытучысы үз өстенә алсын инде! Без баланың сәламәтлеген сакларга, өстен-башын, тамак туклыгын тәэмин итәргә дә тиеш бит әле!

Мондый фикердә торучы ата-аналарга иң элек шуны аңлау кирәк: сүз мәктәп программасына кергән, дәреслекләрдәге әсәрләрне уку турында бармый. Хәер, дәрес хәзерләүдә дә әти-әнинең күзәтеп торуы, киңәшләр биргәләве бик кирәк.

Баланың дәрес хәзерләүләрдән, уеннан, өй эшләреннән бушап калган һәм җанын кая куярга белми аптыраган сәгатьләре дә була. Тәрбиягә оста ата-аналар нәкъ менә шул вакытны балага матур әдәбият китаплары укыту өчен файдаланырга тиеш тә. Бу гадәткә кечкенәдән, хәтта әле мәктәпкә кергәнче үк өйрәнгән бала, тора-бара китапсыз яши алмый башлый. Әти-әнисе алып кайтып биргән рәсемле кечкенә китапларны, әкренләп, зуррак әсәрләр, тормышчан һәм эстетик кыйммәткә ия булган томнар алмаштыра. Бала үз китапханәсен арттыра бара, шулай ук мәктәп һәм шәһәр китапханәләренә йөрергә дә өйрәнә.

Ләкин бала еш кына аңлап җитүе кыен булган китапларга тап була. Мондый китапларны укудан файда аз. Кайчак исә, яшенә караганда, ул инде аңларга тиешле әсәрдән дә баланың ялгыш нәтиҗә ясавы мөмкин. Укуның бу четерекле якларыннан саклап калу өчен дә, китап белән бала арасындагы дуслыкны ныгыту өчен дә әти-әниләрнең күзәтүе, кирәк чакта, ярдәмгә килүе кирәк.

Класстан тыш уку мәктәптә дә бар. Әсәрне уку балаларга максималь файда китерсен өчен, без, әдәбият укытучылары, мондый укуларны алдан төзелгән план белән, әңгәмә рәвешендә алып барабыз. Дөрес оештырылган уку гаҗәп нәтиҗәләр бирә. Балалар айлар буе шул әсәр тәэсирендә йөриләр, ә аның төп кыйммәте — күңелне сафландыруы исә кешегә гомерлек юлдаш булып кала.

Бу максатка ничек ирешергә соң? Китапларда алга сөрелгән кирәкле идеяләр, әдәби образларны бизәүче яхшы сыйфатлар бала холкына сең-

Алсу, мәктәптә укыганда ук, иң гадәти бер клубның драма түгәрәгенә йөри. Һәвәскәрләрнең бер спектаклен театрның тәҗрибәле артистлары Рәшидә Җиһаншина белән Һидаят Солтанов карый. Көннәрдән бер көнне Алсуны театрга чакырталар. Килә. Театрның баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов кабинетында имтиханга охшаш тикшерү башлана.

— Шигырь сөйлә әле! — диләр.

Алсу сөйли.

— Җырлый беләсеңме!

Алсу үзе булдыра алганча җырлап та бирә.

— Спектакльдән өзек уйнап күрсәт әле!

Уйный Алсу.

Сынаучылар үзара киңәшәләр дә:

— Без сине театр училищесының икенче курсына алабыз, — диләр.

Ул арада урта мәктәптә өлгергәнлек аттестатына имтихан бирер чак җитә, училищедагы укулар катлауланып килә. Алсу, елап, Рәшидә апа янына керә.

— Булмый миннән, китәм, — ди.

— Ник!

— Бик авыр, чыдар хәлләрем калмады. Артист буласым да килми.

— Авырлыклардан курыксаң, беркем дә була алмассың, — диләр аңа. — Тырышып кара әле, бәлки җиңәрсең!!

Алсуны Марсель Сәлимҗанов үзе укыта. 1974 нче елда актриса Академия театрына эшкә билгеләнә. Улы Искәндәрне аякка бастыруга киткән вакытны алып ташласаң, Алсуның театрда ныклап иҗат итүенә әле ике генә сезон. Шул кыска ара эчендә ул хәтергә уелып калырлык образлар тудырып өлгергән: Агазия («Ташлама утны, Прометей»), Зөһрә («Мулланур Вахитов»), Гөлчирә («Ташкыннар»), Кеккина («Хатыннар гайбәте»), Әлмира («Суган суфые»)... Арада иң кадерлесе, әлбәттә, Шәфика роленәдәге кичерешләр («Я кайтырбыз, я кайтмабыз»).

Бер карасаң, Гайнуллинаның иҗат юлы бер-бер артлы килгән бәхетле очраклардан башланып киткән төсле. Ярый ла күреп алганнар, ярый ла Марсель Сәлимҗанов классына эләккән, ярый ла тарихи театрга эшкә алганнар, ярый ла әйбәт рольләр биргәннәр. Өстәвенә, аңа талантлы артист Илдар Хәйруллин гашыйк булган, өйләнешкәннәр, баласына да дүрт яшь тулып килә.

Тик берсе артыннан берсе агылып торган бу шатлыклы хәлләр актрисаның зиһенен томаламаган. Алсу, бәхеткә каршы, бу беренче куанычлар артында нинди зур җаваплылыклар сагалап торганын яхшы аңлый. Ул үзенә тапшырылган хезмәткә баштан-аяк бирелгән. Аның өчен сәнгатьтән дә, халыкка хезмәт итүдән дә изгерәк нәрсә юк. Яңа роль тапшырдылармы, тормыш ыгы-зыгылары да, гаилә мәшәкатьләре дә, хәттә нәни Искәндәргә бәйле борчу-шатлыклар да икенче планга күчә. Актрисаның бөтен барлыгы театр таләпләренә буйсындырылган. Агазия ролен оста башкарганы өчен аңа Бөтенроссия фестиваленең 1 дәрәҗә дипломы бирелгән икән, монда инде һичнинди очраклылык та юк.

Дөрес, Алсу Гайнуллинаның моңарчы башкарган һәр роле — аның яшьтәшләре. Ләкин холыклары ягыннан алар бер-берсенә һич охшамаганнар. Актриса аларның һәрберсен үзләренә хас сыйфатлар белән бизи, кабатланмас образлар итеп гәүдәләндерә. Кыенлыклар хәзер аны куркытмый, киресенчә, катлаулы образлардан ул аеруча ләззәт таба, эзләнә, табышларын алдагы җиңүләргә баскыч итеп файдалана белә. Алкышларны исә ул күп кыенлыклар аша ирешелгән җиңүнең бик кыска бер мизгеле генә итеп таный.


Тамашачы актерның тәмам өлгергән эшен генә күрә. Ял сәгатендә, иркен залда, йомшак кәнәфигә чумып тамаша карап утыру чиксез рәхәт! Мөгаен, шуңлыктандыр, яшьләр арасында: «Артист булыр идем!» — диючеләр бихисап. Мөмкинлек чыгып, үзенә яңа роль тапшырылган артистларның бәргәләнә-бәргәләнә эзләнүләрен, теләгән алымнарны таба алмый газапланулары да күрергә туры килсә, артист хезмәтенә мөнәсәбәт үзгәрер иде.

Алсу Гайнуллина, әле яшь-яшь булуына да карамастан, бу хакыйкатьне тирәннән аңлый.

Талантлы хатын-кызлар фидакарьлеге татар театры тарихына гаҗәеп матур сәхифәләр теркәгән: Сәхипҗамал Волжская, Гөлсем Болгарская, Нәгыймә Таҗдарова, Гөлсем Камская, Нәфига Арапова... Халыкчан сәнгатькә тугры булу бу талант ияләрен үлемсез иткән. Бүген дә сәхнәбезгә уннарча талантлы артисткалар хезмәт күрсәтә. Алсу Гайнуллина да кыю рәвештә әнә шулар рәтенә килеп кушылды. Аның да татар сәхнәсе маякларына, сүзебезнең башына борылып кайтып әйтсәк, Әлмәндәрләр токымына лаек булуына өмет тотыйк!

Кояш ТИМБИКОВА.

ЯРАТАМЫ?



сен, аның уй-фикер йөртүенә уңай йогынты ясасын өчен нишләргә?

Әлбәттә, әсәр турында сүз кузгатканчы, бала укыган китап белән әтиәниләрнең танышкан булуы кирәк. Югыйсә, ничек ул әсәр турында аңгәмә корасың яки бәхәсләшәсең инде? Әйтик, сезнең улыгыз яки кызыгыз Галимҗан Ибраһимовның „Алмачуар" хикәясен укып чыкты, ди.

Беренче сүз әсәрнең авторы хакында барырга тиеш. Кем ул Галимҗан Ибраһимов? Аның тагын нинди әсәрләре бар? Бу ниндирәк мәсьәләләрне күтәрүчән, нинди образлар белән эш итүче язучы соң? Баланың яшенә карап, сорауларны катлауландыра төшәргә, язучының дөньяга карашы, аның Бөек Октябрь революциясендә катнашуы, Ленин белән очрашуы хакында да сөйләшеп алырга ярый. Алга куелган сорауларга бала үзе җавап бирсә әйбәтрәк. Җавапларны тулыландыру гына — әти-әнигә тапшырылган бурыч.

Акрынлап әсәр турында фикер алышуга күчәсең. Бу очракта: „Син ничек уйлыйсың, Г. Ибраһимов «Алмачуар» хикәясен ник язган?», «Язучы бу тайны үзе яратамы, синеңчә?», «Син дә шундый тай тәрбияләр идеңме?», «Авыл табигатен яратасыңмы син?» «Табигать матурлыгын шулай оста тасвирлаган тагын нинди әсәрләр бар икән?»

Сораулар маңгайга бәреп бирелмәскә, үзара сөйләшү, аңлашу, фикер алышу формасында гына әйтелергә тиеш. Бер сорауга тулы җавап табылып бетмәсә, ашыгырга ярамый. Баланың уйлануын, эзләнүен көтәргә, аз-азлап булышырга кирәк.

Атнага бер генә көнне бернечә сәгать вакытыгызны кызганмыйча, шундый укулар оештырсагыз, тәрбия юлында очрый торган күп мәсьәләләр сезнең баш ватуны сорамас та иде. Бу очракта баланы инсафлы, ярдәмчел, кешелекле, сүзендә торучан, матурлыкка омтылучан, олыларны хөрмәтләүчән итеп үстерү вазифасын китаплар үз өсләренә алалар.

Надежда ИЛЬЯСОВА,
134 нче мәктәп укытучысы.
Казан.

МЕҢ ДУСТЫҢ БУЛСЫН

«Кадерле редакция! Миңа Зәйнәп Якупованың журналның узган елгы 5 нче санында басылып чыккан «Әгәр син җитәкче булсаң» дигән мәкаләсе бик ошаган иде. Бу мәкалә өчен Зәйнәп Якубовага бик зур рәхмәт, миңа ул күп мәсьәләләрне хәл итәргә булышты. Дөрес, мин әллә ни зур җитәкче түгел, бригадир гына, әммә кул астында эшләгән 22 кеше, нинди генә кыенлык туса да, миңа килә.

Тагын бер мәсьәләдә ярдәм итсәгез иде. Мин — ир кеше, семья башы, миңа 40 яшь, ике кызым бар. Тормышыбызны күреп кеше сокланырлык. Ә шулай да миңа нидер җитеп бетми кебек. Элек минем аралашкан өч-дүрт дустым бар иде. Мин үзем дә эчмим-тартмыйм, дусларым да бик әйбәт кешеләр, югары белемлесе дә бар, үзем кебек сигез классльысы да бар. Барысы да гаиләле. Элегрәк бу дусларым безгә килеп йөриләр иде. Соңгы елларда исә болар сагынып сөйләргә генә калды. Минем дусларым хатыныма ошамады. Дөрес, мин башта аларның бездән ник бизгәннәрен сизмәдем, ә уйлап карасам, хатын аркасында икән. Ул аларга тупаслык кылмаса да, якты чырай күрсәтми, салкын кылана иде, турыдантуры әйтмәсә дә, яратмаганлыгы сизелә иде. Хәзер беркем дә безгә аяк басмый инде. Ә хатыным, семья үзе генә яшәргә тиеш, дип уйлый. Безнең кайсыбыз хаклы икән?

А. САБИРОВ».

Укучыбызның бу соравына медицина фәннәре докторы, профессор Зәйнәп ЯКУБОВА җавап бирә.

Тегеләй итегез дә болай эшләгез, дип киңәш бирергә керешкәнче, мин тормышта булган бер вакыйганы сөйләп китмәкче булам.

Асия белән Ризван икесе ике төрле холыклы кешеләр иде. Асия институтка керде, бик тырышып укый, үзен бик тыйнак тота иде. Ризван исә инде вузны тәмамлаган, үзенчә «матур» итеп яшәргә, кеше белән аралашырга ярата иде.

Бергә яши башлауларына ике-өч ай үтмәде, Асия бик боегып китте. Мин аның белән сак кына сөйләшергә булдым. Һәм ул миңа менә нәрсәләр сөйләде.

Ризван кичләрен өйдә тормый икән, кайчак төнге сәгать икеләрдә-өчләрдә кайта, үзе генә түгел, иптәшләрен ияртеп кайта. «Ә мин ул чакта укып утыра торган булам, ирем озак йөргәнгә күңелем төшенке була, — дип сөйләде Асия. — Алай да кеше алдында сер бирмәскә тырышам, елмаеп каршы алам, ашыйсыгыз киләме, дип сорыйм, табын әзерлим. Аларны сыйлап-көйләп озаткач, үзем гарьлегемнән кухняга бикләнеп елыйм. Ә ирем моны белми дә кала, чөнки дуслары чыгып китүгә ятып йоклый. Әллә аерылыйммы икән, күңелем бик рәнҗи!» — дип тәмамлады сүзен Асия.

Мин аны кулымнан килгәнчә юаттым. Әлбәттә, төн урталарында кунак алып кайтып, Ризван дөрес эшләми, ул синең белән исәпләшсә, кунакларны җайлырак чакта алып килсә, яхшы булыр иде, дидем. Алай да иреңнең дусларын хөрмәтләп, син бик дөрес эшлисең, сабыр ит, төшенкелеккә бирелмә, гаилә тормышы беркайчан да шома гына бармый, һәркемнең үз кыенлыклары була, дидем.

Вакыт үтте. Асия институтны тәмамлады, әкренләп үзгәрде, кыюланды. Аның гаилә тормышы матурланганы күңеле көрлегеннән үк сизелеп тора иде.

Шактый вакыттан соң гына мин аларның мөнәсәбәтендә зур борылыш булганын белдем.

Бердәнбер көнне Ризван төн уртасында ап-аек килеш, бик күңелсезләнеп, берүзе кайтып керә. Хатыны, ни булды, дип сораша, теге дәшми. Ләкин шул көннән соң соңарып кайтудан туктый, күбрәк Асия янында була башлый.

Моның хикмәте менә нәрсәдә икән! Ризван, бер кыз белән мавыгып, аны озата барган, аннары бер дустының өенә кергән, «Әйдә, мине өйгә озатып куй әле, синең белән кайтып керсәм, хатын ачуланмас, мине кырын юлда йөргән, дип тә уйламас», — дигән. Дусты моңа беразкарап торган да: «Утыр әле», — дигән һәм телефон трубкасын алып, тагын бер дустына шалтыраткан: «Хәзер үк безгә килеп җит!» Тегесе шундук килеп тә җиткән. Хуҗа үзенең хатынына: «Син бераз чыгып тор әле, без монда ирләрчә сөйләшеп алыйк», — дигән.

Өч ир-егет, өч дус, күзгә-күз карашып, Ризванның гаиләсе, аның үз-үзен тотышы турында сөйләшкәннәр. Ниләр әйтелгән анда Ризванга! Монысы инде шул өч ир-егет, өч җан дус арасында сер булып кына калган. Әгәр инде кешенең үз-үзен тотышын, гаиләсенә карашын тамырдан үзгәртә алганнар икән, димәк, сүзләрнең дә беркем таба алмаслыгын әйткәннәр. Хәер, ничә еллар Асиянең сабырлыгын, яхшылыгын күреп, күпме ризыгын ашаган кешеләр бит алар! Андый кешеләр дус күңеленә ничек ачкыч тапмасын!

Менә шул чакта Ризванның дуслары Асиянең яхшылыгын меңе белән кайтаралар, ә хатын бу хакта белми дә кала.

Тик берничә еллар узгач кына, мин бу хәлләрне белдем һәм: «Әгәр алар булмаса, Асия гаиләсен югалтыр иде бит, ә хәзер менә ничек матур яшиләр!» — дип алар өчен куандым.

Мин бер генә мисал китердем. Юлда, эштә, ялда, авырганда, кайгы-хәсрәт килгәндә дусның дуска кылган ярдәме, дусның дустын мең бәлаләрдән, хәтта үлемнән коткарганы турында бик күп сөйләп булыр иде. Гомумән, дусларсыз яшәп буламыни бу дөньяда! Андый тормышның ни яме дә, ни рәхәте кала!

Дусларны булдыру өчен тормышның бай булуы да кирәкми. Нинди генә шартларда яшәсәң дә, дусларың булсын. Чын дус синең байлыгыңа кызыкмый. Аның өчен сый-хөрмәтнең иң зурысы — якты чырай, такта чәй. Әгәр синең өеңә дуслар килә икән, җиһазың ялтырап тормаса да, алтын-көмешең булмаса да, син — бай, дигән сүз.

Гарәпнең бер мәкале бар: «Ерак юлга чыкканда алтын алма — авыр булыр, ризык күп алма — бозылыр, үзең белән иң якын дустыңны ал», — ди.

Гомер кичү — ерак юл узу белән бер. Ул юлда якын дусларны бер нәрсә дә алыштыра алмый.

Журналның узган елгы октябрь һәм ноябрь саннарында бер-бер артлы ике мәкалә басылды. Берсе әти кешеләрнең гаилә таянычы булырга тиешлеген кисәткән «Атаның гаиләдәге роле», икенчесе әни кешеләргә пөхтә һәм тыйнак булырга кушкан «Күркәм булыгыз» дигән мәкаләләр иде. Сүз әтиләр турында барганда үземә бик таныш булган бер гаиләне һәм андагы атаны күз алдыма китердем. Сүз әниләр турында барганда игътибарым яңадан шул гаиләгә кайтты.

Рабига тормыш дулкынына бәрелеп алган гаиләгә килде. Ашыгып, мәхәббәттән күзе тонып түгел, уйланып, барысын да — бүгенгесен дә, киләчәген дә күзаллап, аның өч яшьлек малаена кыз килеш әни булып килде. Әле дә хәтерли Рабига ул көнне: зәңгәр «матроска» кигән сабый аңа тутырып карап торды да йомылып килеп алдына менеп утырды.

— Син гел елмаясың,— диде ул, икенче көнне әнисенең битен нәни куллары белән сыйпап.

«Бала күңелен яулап алу өчен ягымлы булу кирәк икән», дип уйлады яшь ана.

— Синең алъяпкычың тәти, — диде малай өченче көнне итәгеннән чеметеп.

«Бала да матурлыкны ярата» дип беркетте күңеленә әни кеше.

— Тормыш гел көләчлектән, пөхтәлектән генә тормый, төрле чаклар була... — диде аңа ата кеше, җитди карап. Без ул вакытларда сабыр була белсәк иде...

Озак көттерми, шундый чак та килеп җитте. Яши башлауга өч ай дигәндә Рабига эштән күңеле төшеп кайтты. Салкын тидергән. Бер атнага бюллетень биргәннәр. «Мин сиңа җылырак киенергә кушкан идем»,— диде аңа ире, җитди генә. Сүз артыннан сүз китте, ике арадагы кырыслыкны тойган сабый боегып почмакка барып утырды.

— Бала алдында үзара тупасланырга ярамый, — диде әни кеше.

КЕМ

Бөек рус галиме И. И. Мечников, кеше бик рәхәтләнеп йөз алтмыш яшькә кадәр яши ала, дигән фикер әйткән. Табигатьтә озын гомерле бик күп җан ияләре бар. Мәсәлән, карга — 100, крокодил 300 ел яши. Агачлар исә тагын да озынрак гомерле: имән — 1000, секвойя 2000 ел буе үсеп утыра. Тереклек дөньясының хуҗасы, табигать патшасы булган кеше генә бик аз яши.

Көннән-көн үсә барган медицина фәне һәм врачлар күп кенә авыруларны җир йөзеннән бөтенләй юк иттеләр. Безнең илдә кеше гомере уртача 70 яшькә җитте. Ләкин бу галимнәр куйган санның яртысын гына да тәшкил итми бит әле. Иң гаҗәбе шул: тикшерә китсәң, озак яшәү мөмкинлегенә, иң беренче булып, кеше үзе аяк чала.

Дөнья бер бөтен булган кебек, табигатьтә дә һәрнәрсә бер-берсенә бәйләнгән. Бер каршылык икенче каршылыкны тудыра, бер күңелсезлек икенчесенә сәбәп була. Галия дә ул көнне

ГАИЛӘ КӨЗГЕСЕ

— Беркайчан да ярамый, әнисе, — диде аңа әти кеше.

Бу сүзләрнең мәгънәсен мин, укытучы буларак, тирәнтен аңлыйм. Баладан да сизгер кеше юк гаиләдә. Аларны



тәрбия итәргә, кеше булып үсүләрен теләсәң, иң башта үзең үрнәк күрсәтергә тиешсең. Хәй Мушинскийлар гаиләсе тора-бара ишәя төште. Кызлары туды, янәдән бер малай дөньяга килде. Туганнар һәм дуслар арасында үрнәк итеп күрсәтердәй тату яшәделәр һәм шулай яшиләр дә алар. Үзләре һәр икесе дә сәнгать кешеләре — артистлар. Дуслар җыела, табыннар җәелә. Ә балалар алдында өстәлгә хәмер куйганнарын күргәнем булмады. Монда әти кешенең дә роле зур булгандыр. «Үзең теләп вакытлыча акылдан язу» дип атый ул вино эчүне. Шуның өстенә өч бала йөгереп йөргән бу квартирадагы җыйнаклыкка исем китә иде минем. Балаларның өс-башы һәрчак пөхтә. Хәтта аларның урамнан уйнап кайтканда да тузанга, яки карга батып кайтканын хәтерләмим.

Ә бит бала, үтүкләнгән чалбардан, чиста күлмәктән булса, беркайчан да теләсә-кая утырырга, аунарга кыймый, бу аларга кечкенәдән эстетик тәрбия бирә. Шуның өстенә арада ике-өч кенә яшь булса да алар бер-берсен зурларга өйрәнделәр. Олы уллары Фоат сеңелесе Раилә, энесе Әхәткә дә «өлкән абый» булып үсте. Ун яшьлек малай кечкенә туганнарының өйгә вакытында кайтуларын таләп итә, дәрес хәзерләүләрен күзәтә иде. Ә ата-аналары аларның өчесе белән дә җитди тонда сөйләшәләр, сабый итеп түгел, аларга олы кеше итеп карыйлар, кечкенәдән эшкә өйрәтәләр иде. Моның да серенә төшенү ансат: бала кечкенәдән үзенә карата җаваплылык хисе тоеп, эшкә өйрәнеп үсәргә тиеш. Әгәр киресенчә булса, ул башта ата-анасы җилкәсендә, соңыннан җәмгыять хисабына яшәүче ялкау бер имгәк булып калырга мөмкин. Балалар үстеләр, кеше булдылар. Фоат — инженер, Раилә хисаплау машинасында эшли. Әхәт — журналист. Хәзер инде һәр өчесенең дә үз гаиләсе, үз балалары бар. Хәй белән Рабига инде пенсиядә. Балалары белән кунакка йөрешеп, гөрләшеп яшиләр. Ә бит уйласаң, күркәм холыклы, үзләре кебек акыллы балалар тәрбияләгән бу хөрмәтле кешеләргә тормыш ал да гөл булып елмаеп кына тормагандыр. Хезмәтләре авыр да, җаваплы да иде аларның. Рабига Мушинская Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында 39 ел буе хор солисткасы булып эшләде. Ул эшли башлаганда герой-шагыйрь Муса Җәлил үзе театрның әдәби бүлек мөдире иде. Филармониянең иллюзионист артисты Хәй Мушинскийның исеме дә күпләргә таныш. Күпме гастрольләрдә йөрелгән, күпме кичләр театрда узган, аерылышып торулар, сагынышып кайтулар булган. Гаилә татулыгы бозылмаган, балалар тиешле тәрбия алып кеше булып аякка басканнар.

— Гаиләне саклау хатын-кызның төп бурычы, — ди Хәй бу хакта сүз барганда, — бөтен гомерем акыллы, уңган хатын белән уза. Мин үземне бәхетле иргә саныйм.

— Гаиләгә акыллы, аек ир кирәк. Мин аңа тап булдым, — ди Рабига, — атасы нинди, баласы шундый, — диләр, — мин дә үземне бәхетле ана итеп сизәм.

Мөкәррәмә АЗАМАТОВА.

НЕ ШАТЛАНДЫРДЫҢ?

нәкъ вакытында эшкә җыена башлаган иде. Әнисе мең дә беренче киңәшләрен бирә башлады. Тегеләй эшләмә, болай итмә, эштән вакытында кайт. Галия үзүзен тыеп кала алмады, «Туйдырдың инде!» — дип кычкырды да ишекне шап итеп ябып чыгып китте. Трамвайда ул ике хатынның кычкырышуына тап булды. Тукталыштан эш урынына җиткәнче, каты итеп сызгыртып баручы ашыгыч ярдәм машинасы очрады. Яныннан гына баласын елата-елата бер ана узды. Эшкә килеп кергәндә Галиянең нервлары тәмам чуалган иде. Берәүне дә күрәсе, берәүгә дә сәлам бирәсе килми. Мастерның кәефе башкаларга да күчте. Смена азагына көнлек норманың үтәлмәгәнлеге беленде. Ниһаять, Галия эштән авыруга сабышып кайтып керде. Кайтырмын да ятармын, дип уйлаган иде. Ләкин аны өйдә көтмәгәнчә каршыладылар. Бүлмәләр ялт иткән, кухняга пәрәмәч исе таралган. Улы Галияне кочаклап алды, ире аңа чишенергә булышты. Ул арада әнисе табын әзерләде, өстәл янына кичке ашка җыелдылар. Җанны рәхәтлек биләп алды, башкаларга кушылып көлде, сөйләшеп утырды. Ләкин Галиягә бер уй тынычлык бирми иде. «Әгәр кеше гомере китап булып, һәр көне аерым бер биткә язылса, мин анда бүгенге көнне язмас идем», дип уйлады ул. Бүгенге көне үкендерә иде аны. Ә үкенү эзсез үтми. Беренче чиратта нерв системасы зарарлана. Галия инде көндезге хәлләрне искә төшермәскә тиеш иде кебек. Булдыра алмады. Ул әле һаман әнисен гаепли. Чыннан да, кем гаепле соң? Галия үземе, әнисеме? Әгәр иртән Галия әнисенең сүзләрен елмаеп кына үткәреп җибәрсә, яки аның башына: «Мин әни урынында булсам, ни эшләр идем» дигән уй килсә, күпме кешенең кәефе бозылмый калыр иде. Ә 80 яшьлек әби үзен кызы урынына куеп караса да, алар, мөгаен, җиңелрәк аңлашырлар иде.

Кайбер илләрдә производство җитәкчеләре гел елмаеп торырга тиеш. Елмаймаса, эшченең кәефе китә, сыйфат начарлана. Польшада «Елмаю медале» уйлап чыгарулары да кызыклы. Ул медаль белән кешеләргә кем күбрәк яхшылык эшли — шатлык өләшә, шул бүләкләнә.

Кеше күңеленә ялгыш кагылу әллә нинди давыллар кузгата. Бер җылы сүз канатлы итә, мәңге яшисене китерә. Матур, зур дөньяда кайвакыт без артык вакланабыз. Бер-беребезнең кәефен бозабыз. Хисләребез белән идарә итә белмичә ялгышабыз. Кеше гомерен озынайту өчен больницалар, дарулар, хәтта иң шәфкатьле врачларның да ярдәме аз. Кешегә җылы сүз, ягымлы мөгамәлә, өзлексез кайгыртучанлык күрсәтү кирәк. Тирә-ягыбызда яхшы кешеләр барын тойсак, эчкерсез елмаюлар гына күрсәк, эшебездән илһам тапсак, без нәкъ менә 160 яшькәчә яши алыр идек. Организмыбыз моңа түзә, ди медицина.

Ф. ХУҖИӘХМӘТОВА.



Врач җавап бирә

«Врач булу, кешеләрне дәвалау — иң игелекле һөнәрләрнең берсе. Шуңа күрә минем врач буласым килә. Мин хәзер 10 нчы класста укыйм. Врач булу өчен миңа нишләргә, нинди фәннәрне аеруча нык укырга кирәк!

Фәйрүзә З.
Чакмагыш районы».

Мәгълүм булганча, врачларны медицина институтлары әзерли. Бу институтка керү өчен, иң беренче чиратта биология, физика, химия фәннәрен яхшы белергә кирәк. Болардан тыш рус теленнән язма — сочинение (татар мәктәбен тәмамлаган балаларга изложение) рәвешендә имтихан тапшыралар.

Ләкин, врач булу өчен, беренче чиратта кешеләрне яратырга, түзем, сабыр, ярдәмчел булырга кирәклеген онытырга ярамый. Врачлар кешеләрне сихәтләндереп, рәхмәт ишетеп кенә яшиләр, дип уйламагыз. Әҗәлне җиңә алмаудан гаҗиз калып, үлем түшәгендә яткан кешеләрнең газапларын җиңеләйтергә дә туры килә аларга. Гомумән, авыру кешеләрне караунын кыенлыклары да, нечкәлекләре дә бик күп. Врач булу турында хыялланган яшьләр моны аңласыннар иде. Гомумән, алар бу эштә үзләрен сынап карасыннар, әйтик, больницаларда санитаркалар булып эшләсеннәр. Шуннан соң гына, кешеләрне дәвалаудан үзләренә куаныч алачакларына, башкаларга җиңеллек бирәчәкләренә ышангач кына, медицина институтының ишеген килеп каксыннар иде.

Медицина институтларында берничә факультет бар. Берсе врачлар дәвалау эше белән шөгыльләнсә, икенчеләре санитария-гигиена эше белән шөгыльләнә. Шулай ук теш врачлары, балалар врачлары әзерли торган бүлекләр дә аерым була.

Институтлардан тыш, медицина училищелары да бар. Анда фельдшерлар, акушерлар, медицина сестралары, лаборантлар әзерлиләр. Бу уку йортларын бетереп, бераз эшләгәч, институтка керергә мөмкин. Монысы үзеңнең теләгеңә һәм тырышлыгыңа карый.

* * *

«Мине бакчада корт чаккан иде. Шуннан соң йөрәгем авыртты, тыным кысылды, бөтен тәнем кычытып чабырды. Бу нилектән икән!

Азат Ж.
Әгерҗе».

Бал корты агуының организмга тәэсире бик катлаулы һәм әлегә тулысынча өйрәнелмәгән. Бу тәэсир агуның күләменә, кортның кай урынны чагуына һәм организмның үзенчәлегенә бәйле. Бал кортының агуы канга бик тиз сеңә. Күп очракта корт чаккан урын аз гына кызарып чыга, шешә, әмма бик тиз төзәлә. Кайбер кешеләр, мәсәлән, умартачылар, корт чагуга күнегеп бетәләр. Ә кайбер кеше исә корт чагуга чамадан тыш сизгер була. Сизгерлек төрлечә: берәүләрнең тәне кычыткан чаккан кебек бөртеп чыга, кайберәүләрдә хәтта тын кысылу да булырга мөмкин. Корт чагу бер очракта файдалы булса, башка очракта (зур дозада) зыянлы. Ә берәттән йөзләгән (500 ләп) корт чакса, кеше үләргә дә мөмкин. Берничә корт берәттән чакканда, кешенең башы әйләнә, косасы килә; ул тирли, эче китә башлый, кан басымы төшә, тәне кызыша. Кайбер очракта аңын югалтырга да мөмкин.

Сирәк очракларда кайбер кешеләрнең организмында корт агуына карата аллергия, ягъни түземсезлек була. Аллергия корт чаккан саен көчәя, шуңа күрә бу мәсьәләдә игътибарлы булырга кирәк. Корт чаккач, хәле начарайган, тыны кысылган, тәне чабырган кешеләргә, әлбәттә, аллерголог врачка күренеп, ул әйткәнчә дәваланырга кирәк.

Аз дозада һәм акрынлап чактырырга өйрәнгәндә, кайбер авырулардан корт чагуның файдасы да бар. Ул матдәләр алмашу һәм йөрәк эшчәнлеге яхшыруга китерә. Корт агуы кайбер мазьлар составына да керә. Андый мазьларны, ревматизм, полиартрит, радикулит кебек авырулар булганда, тәнгә сөртәләр. Авырлы хатыннарга, йөрәк авыруының авыр стадияләрендә, нерв системасы, бавыр-бөер, туберкулез авырулары белән авырган кешеләргә бал корты агуы катнашмасы булган мазьлар кулланудан сак булырга кирәк.

Турыдан-туры корт чактыру белән дәвалау да киң таралган. Бер-ике мәртәбә корт чактырып, аның кешегә ничек тәэсир иткәнен күзәткәннән соң, бер ай буе көн аралаш корттан чактыралар. Шундый бер циклдан соң, ай ярым-ике ай ял итәргә кирәк. Аннан корт чактыруны дәвам иттерәләр. Корт чаккач, аның угын бер сәгатьтән соң гына алалар. Корт чагу белән дәваланган кеше көненә 100 грамм чамасы бал ашаса, аның шифасы тагын да арта төшә.

Корт чактырып дәвалана башлаганчы, врач белән киңәшергә кирәк.



Һәркайсыбызга мәгълүм: сигезенче март көнендә ир-егетләр хатын-кызларга гадәттәгедән зуррак кадерхөрмәт күрсәтергә тырыша. Бу көнне өйне гаилә башы — ир кеше җыештыра, елның башка көннәрендә кухня-казан тирәсенә: «Кая, ашың кайчан әзер була!» — дип сорар өчен генә керә торган булса да, сигезенче мартта сыйны үз кулы белән әзерли. Һәм, әлбәттә, ир кешенең йөз кызартасы килми, тәм-томиның менә дигәнен пешереп мактанасы, үрнәк күрсәтәсе килә. Гомумән, кайбер ир-егетләр, ир пешекчеләр ашсуны хатын-кыз пешекчеләргә караганда тәмлерәк әзерли, дип сөйлиләр. Үзбәкстанда, мәсәлән, пылауны күпчелек очракларда ирләр пешерә.

Әйдәгез, сез дә сынап карагыз әле, бәлки, чыннан да егетләр кулы кергән аш тәмлерәк була торгандыр.

Пылау пешерү өчен калын, киң төпле, тирән савыт яхшы. Чуен казан булса, бигрәк тә әйбәт. Аңа иң элек майны салып, ак төтен чыга башлаганчы кыздыралар. Аннары аңа туралган итне, аннары туралган суганны, аннары кишерне салып кыздыралар. Ул катнашма зирвак дип атала. Зирвакта һәр ризык алтынсу төскә кереп кызарга, шул ук вакытта үз төсен һәм тәмен сакланган булырга тиеш. Кыздырган чакта, ризыклар казан кырыена һәм төбенә ябышып көймәсен өчен, гел карап, болгаткалап торырга туры килә. Утны вакытында көчәйтеп, вакытында киметеп тору бик мөһим.

Зирвак әзер булгач, аңа тәмләткечләр салалар. Башка ризыклардан аермалы буларак, пылауга су белән тозны бүлеп-бүлеп ике тапкыр салсаң яхшырак. Су белән тозның яртысын салгач, казан астындагы утны әкренәйтәләр. Зирвак никадәр әкренрәк кайнаса, пылау шул кадәр тәмлерәк була. Кайнау җиткәч, зирвак өстенә тигез итеп дөгене җәяләр. Дөге калын катлам булып, зирвакның өстендә ятарга тиеш, аска төшсә, аның казан төбенә ябышып көюе ихтимал. Шуннан соң дөге өстенә ике бармак калынлыгында чыгып торырлык итеп су өстиләр. Суның микъдарын дөрес алу да бик әһәмиятле. Дөге коры булса, суны гадәттәгедән күбрәк салырга туры килә.

Пылау казанда тигез кайнарга тиеш. Су кайнап беткәч, пылауның өстен томалыйлар, утны әкренәйтәләр. Су кайнап беткәнмеюкмы икәнне белү өчен, дөге өстенә тишекле чүмеч белән суккалап алырга була, әгәр саңгырау аваз чыкса, су беткән, дигән сүз. Пылауга таякчык белән чокырлар ясыйлар, аннары тишекле чүмеч белән өстен тигезлиләр. Бу — дөге белән тәлинкә арасында хасил булган парның сеңүе өчен кирәк. Дөге өстен каплаган тәлинкә парны чыгармаслык итеп куелган булырга тиеш.

Шушы кагыйдәләрне төгәл үтәгәндә, пылау таралып тора, гәрәбәдәй алтынсу төстә була, капкач авызда эреп китә һәм телеңне йотардай тәмле була.

Биредә без берничә төрле пылау пешерү ысулын тәкъдим итәбез. Теләгәнегезне сайлап алыгыз.

ФИРГАНӘ ПЫЛАВЫ

Ваклап туралган сарык маен казанга салып эрете-

* * *

«Кайберәүләр минераль-сулар эчеп файда күрүләре турында сөйлиләр. Ул суларны кайсы очракта, күпме эчәргә икән!

Г. Зәйнетдинова,
Түбән өлкәсе».

Минераль су ул җирдән чыга торган табигый су, тик аның составында күп микъдарда минераль катнашмалар — төрле эрегән газлар, ионнар, тимер, мышьяк, йод, бром, кайберләрендә радиоактив элементлар бар. Минераль суларны шул матдәләр шифалы итә дә инде. Төрле суларда эрегән матдәләрнең составы төрлечә була. Шунлыктан минераль сулар үзләренең ачылыгы буенча да бер-берсеннән аерылып торалар. Аларның бер төрләләрен эчәләр, икенче төрлеләрә белән ваннада юыналар. Шифалы сулар белән дәвалый торган күп төрле курортлар бар. Шулай ук минераль суларны шешәләргә тутырып аптека һәм сәүдә челтәрләре аша халыкка сату да киң таралган.

Нигездә шешәле минераль сулар белән төрле хроник авырулар, шул исәптән ашказаны-эчәк авырулары, бавыр, бөвел юлы авырулары дәвалана. Ләкин үз белдегең белән яки таныш-белешләрнең киңәшен тотып дәваланырга ярамый, врач белән киңәшеп, ул кушкан суны эчәргә кирәк. Минераль су эчү белән бергә башка төрле дәвалау чаралары кулланганда (режим, диета тоту, дару эчү, физиотерапия) шифалы су эчүнең файдасы күбрәк була. Өй шартларында минераль су эчеп дәвалану, әлбәттә, уңайлы. Әгәр суны сатып алып сакларга туры килсә, шешәләрне кырын яткырып, салкынча урында сакларга кирәк. Һәрвакыт аның бөкесе юеш булып торырга тиеш — су озаграк сакланачак.

Минераль суларны эчү срогына килсәк, гадәттә, врач, су эчәргә тәкъдим иткәндә ук, нинди авырудан кайсы суны эчәргә һәм күпме эчәргә икәнен аңлатып бирә. Гомумән алганда, шифалы су эчүләр хроник авырулар булганда кулланылганлыктан, аны озак эчәләр. Гадәттә, берәр ай эчкәч, бераз ял тәкъдим ителә, шуннан яңадан эчә башларга була.

* * *

«Йөкле вакытта мин акбур, күмер ашадым, хәзер балам ике айлык инде, ә мин һаман күмер ашамыйча түзә алмыйм. Миңа нишләргә икән!

Разилә К.
Учалы районы».

Ана булу бәхете — хатын-кыз өчен иң зур бәхет. Ләкин ана булу өчен шактый авырлыкларны да җиңәргә туры килә. Иң беренче чиратта йөкле хатыннарның организмында күп кенә үзгәрешләр башлана. Нерв системасы һәм йөрәк эшчәнлегендәге үзгәрешләр яшь хатыннарда әлләни сизелмәскә дә мөмкин, ә менә матдәләр алмашуы үзгәрү шактый сизелә. Күп хатыннарның организмында төрле тозлар, бигрәк тә кальций тозлары җитми башлый. Бу тозлар баланың сөяген эшләүгә китеп торганлыктан, йөкле хатыннарның тешләре төшә башларга мөмкин һәм акбур ашау шул кальций тозы җитмәгәнлектән килә дә инде. Бала туып, организмның нормаль эшчәнлеге башлангач, кагыйдә буларак, акбур ашыйсы килү акрынлап үзеннән-үзе бетә. Ә хәзергә кальций, натрий, калий, фосфор тозларына бай азыклар белән тукланырга тәкъдим ителә. Бу тозларга борчак, бәрәңге, ит, сөт азыклары, яшелчә һәм җимешләр бай. Гомумән, бала имезүче хатыннар төрле-төрле азыклар ашарга, җитәрлек дәрәҗәдә ял итәргә, көндезләрен йоклап алырга, тыныч һәм чиста йөрергә тиешләр. Шулай булса, бала да, ана да сәламәт булырлар.

Ә инде бала имезүдән туктагач та акбур, күмер ашау теләге бетмәсә, ул чакта врачка күренергә кирәк, чөнки бу хәлнең организмда матдәләр алмашуы процессының бозылганлыгы хакында сөйләве дә мөмкин.

* * *

«Миңа 16 яшь. Мин атка атланып йөрергә яратам. Ләкин кайберәүләр миңа: «Кызларга атка атланып йөрергә ярамый»,— диләр. Бу сүз дөресме!

С. Р.
Азнакай».

Ат — кешенең күптәнге дусты һәм ярдәмчесе. Бик күптән барлыкка килгән. Борыңгы заманнардан башлап кеше атны үзенең күп төрле хуҗалык һәм сугыш максатларында файдаланган. Атка атланып йөрү дә бик күптән барлыкка килгән. Элегрәк ат, башлыча, ир кешенең (сугышчының) гомерлек юлдашы булган. Ләкин борыңгы күчмә тормыш шартларында хатын-кызлар да атка атланып йөргәннәр. Казакларда, кыргызларда, монголларда бу әле дә гадәти хәл.

Атта йөрү — спортның шактый киң таралган төре булып та санала. Атта йөрү ярышларының кайбер төрләрендә хатын-кызлар ирләр белән берләттән катнашалар. Дөнья чемпионы Елена Петушкованы гына искә төшерик.

Медицина күзлегеннән карагаңда, кызларга атка атланырга ярамый, дигән сүзнең бернинди фәнни нигезе юк. Мөмкинлегегез була икән, рәхәтләнеп йөрегез, кызлар! Тик шуны да онытмагыз: атта йөрү өчен, әлбәттә, махсус кием, спорт костюмы булдырырга кирәк.

Руфина ФӘТТАХОВА.
Медицина фәннәре кандидаты.

гез, сызыкларын җыеп алыгыз, майны ак төтен чыга башлаганчы кыздырыгыз. Пылау матур кызгылт төстә булсын дисәгез, кайнап торган майга итеннән аерылган сөяк кисәге салырга мөмкин. Ул кызарганчы кайнасын, аннары аны алып ташлагыз.

Кызган майга шакмаклап туралган ит кисәкләрен салыгыз, кызарганчы кыздырыгыз. Шуңа боҗралап туралган башлы суганны салып, кызгылт төскә кергәнче кыздырыгыз. Шуннан соң токмач шикелле озынча итеп яки шакмаклап туралган кишерне салыгыз, кирәкле тозның яртысын салып, зирвакны болгатыгыз, кишер алтынсу төскә кергәнче кыздырыгыз. Аннан соң кирәкле суның яртысын салып, кайнатып чыгарыгыз. Шуннан соң зирвакка төрле тәмләткечләр — кара борыч, кызыл борыч һ. б. — салырга була. Ул 20—25 минут кайнарга тиеш.

Дөгенең чүп-чарын чүпләп алыгыз, ике уч арасында сак кына ышкыйышкый салкын яки җылы суда өч-дүрт тапкыр юыгыз. Аннары аны әзер зирвак өстенә тигез итеп җәегез һәм, шунда ук утны кечәйтеп, кирәк кадәр су өстәгез. Су дөге өстенә 1,—1,5 сантиметр чыгып торырга һәм тигез кайнарга тиеш.

Су кайнап беткәнче, аның тәмен татып карагыз, кирәк икән, тоз өстәгез. Су кайнап беткәч, пылауның өстен пар чыкмаслык итеп тыгызлап каплагыз. Утны киметегез. Пылауның бу төре каплап куйганнан соң 20—25 минут үтүгә пешеп җитә. Тәлинкәгә алганда, аңа җыелган тамчыларны пылау өстенә тамызмаска тырышыгыз. Әзер пылауны әйбәтләп болгатыгыз да, зур тәлинкәгә салып, табынга чыгарыгыз.

Пылау торма салаты белән тәмле була (торманы эре кыргычта уып, тәменчә каймак һәм тоз салып болгаталар).

1 кг дөгегә — ярты кило ит, 250 г май, ярты кило кишер, 4—5 баш суган, тәменчә тоз, борыч, тәмләткечләр алына.

ЙӨЗЕМЛЕ БОХАРА ПЫЛАВЫ

Нык кыздырылган майда суганны кыздырыгыз, аннары токмачлап туралган кишерне салыгыз, болгатыгыз, су өстәгез, кайнап чыккач, тоз салыгыз.

Пылау өчен кулләгәдә киптерелгән төшсез ак йөзем әйбәт. Аны чүп-чарыннан чистартып, яхшылап юыгыз да казанга салыгыз.

Дөгене тозлы суда юыгыз, казан астындагы утны киметеп, зирвакка салыгыз. Калганын алда сөйләгәнчә эшләргә кирәк.

Бу пылауны да өстәлгә зур савыт белән куялар. Ул редис салаты белән тәмле.

1 кг дөгегә — 250 г май, 150 г йөзем, 2—3 баш суган, ярты кило кишер, тәменчә тоз кирәк.

САРЫМСАКЛЫ ПЫЛАУ

Сарымсаклы пылауны да алда күрсәтелгәнчә пешерәләр: кызган майга башта ит, аннары суган, аннары кишер салалар. Сарымсак башларының төбен кисеп алыгыз, тышкы кабыгын әрчегез, уртасыннан сабагын алыгыз, салкын су белән юыгыз.

Казанга дөгенең яртысын салып тигезләгез, аның өстенә сарымсак башларын тезегез, өстенә калган дөгене салып, су өстәгез дә пешерүне дәвам итегез. Сарымсакны дөгегә батырып куеп та була.

Пылау әзер булгач, сарымсакларны алыгыз, пылауны болгатып, тәлинкәгә салыгыз. Сарымсак бүлемтеләренең кабыгын әрчеп, пылау өстенә тезегез.

Бу пылау янына помидор суы кую яхшы.

1 кг дөгегә — 300 г ит, 200 г сарымсак, 250 г май, 400 г. кишер, 3—4 баш суган, тәменчә тоз һәм тәмләткечләр кирәк.

Баш редактор —
В. Ф. Ихсанова.

Редколлегия членнары:
Н. З. Закирова
Ә. Ш. Мусина
Л. М. Мәһдиева
И. Г. Сункишева
С. Г. Сөләйманова
К. Г. Шәмсетдинова
Г. Ш. Шәрәфетдинов
(баш редактор урынбасары)
И. Г. Юзеев
З. Н. Якубова
Р. А. Җиһаншина

Художник
Х. Әхмәтҗанов.

Техник редактор
Э. Әдиатуллина.

Общественно-политический и литературно-художественный журнал «Азат хатын» («ОСВОБОЖДЕННАЯ ЖЕНЩИНА») на татарском языке.

Производствога бирелде 20/I-1978 ел.
Басарга кул куелды 6/III-1978 ел.
Тираж 364.000.
Заказ В-7.
ПФ 07027.
Кәгазь форматы 60×90$^{1}/_{8}$.
Күләме 3 басма табак.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан,
Декабристлар урамы, 2.

ТЕЛЕФОННАР:

хатлар һәм авыл хуҗалыгы бүлекләре — 3-07-46;
промышленность, пропаганда, әдәбият һәм сәнгать бүлекләре — 3-07-42;
художник — 3-07-44;
фотокорреспондент — 3-07-67;
җаваплы секретарь — 3-57-69;
кабул итү бүлмәсе — 3-07-40;
баш редактор — 3-58-75.



БЕЗНЕҢ АДРЕС:
г. Казань — 420066,
ул. Декабристов, 2
редакция журнала
«АЗАТ ХАТЫН».

ФӘН ЮЛЫНДА ШӘҺИТ БУЛГАН

Аны бер күрер өчен, сүзен тыңлар өчен чит ил кешеләре Искәндәрия шәһәренә (хәзерге Мисырга керә) ерак юллар үтеп махсус килә торган булганнар. Ул музейда лекцияләр укыганда, халык залга сыймыйча, урамны тутырып басып торган, галим хатын Гипатиянең сүзен колак очы белән генә булса да ишетергә тырышканнар. Чөнки ул, искиткеч укымышлы, акыллы, гаҗәп талантлы булу өстенә, сокландыргыч матур, оста, мавыктыргыч, кызыклы итеп сөйли дә белгән.

Аның белән очрашкан кешеләр Гипатиянең акылына, күркәм фигыленә, сөйкемлелегенә сокланмый кала алмаганнар. Борынгы грек шагыйренең Гипатиягә багышлап язган мәдхиясе безнең чорга хәтле килеп җиткән:

Сине күрсәм һәм тыңласам сүзләреңне,
Нурда коенгандай була күңелем минем;
Чөнки синең гыйлемең һәм гүзәллегең
Бөек һәм саф, йолдызларның нурына тиң.

Бу мәдхия олы талантның, фәнгә багышланган тормышның үлемсезлегенә якты мисал булып тора, чөнки Гипатия моннан мең ярым ел элек яшәсә дә, исеме безнең көннәргә килеп җитте.

Мең ярым ел элек! Шул чорда Гипатия Искәндәрия шәһәрендә философия кафедрасының җитәкчесе була. Хатын-кыз кафедра башында! Күрәсең, аның акылы шундый зур, хезмәтләре шулкадәр күп, абруе шул хәтле югары булган ки, борынгы философлар аны үзләренең җитәкчесе, әйдәп баручысы итеп таныганнар.

Гипатия математик-галим гаиләсендә туып үсә, яшь чакта ук математика буенча әтисен, философия буенча шул чорның барлык галимнәрен узып китә. Ул бик күп фәннәр, шул исәптән астрономия белән кызыксына. Аның төрле өлкәләрдә ясаган ачышлары гасырлар буе үз кыйммәтен югалтмый. Мәсәлән, сыекчада эрегән матдәнең микъдарын билгеләүче приборны — ареометрны ул уйлап чыгарган, дип сөйлиләр. Бу прибор хәзерге көндә дә кулланыла. Гипатия уйлап чыгарган астролябия — ачык диңгездәге корабның урынын билгели торган прибор — XVIII нче гасырга кадәр диңгезчеләр кулыннан төшмәгән.

Мондый зур галим үз чорында ук бар халыкның мәхәббәтенә, зур ихтирамына лаек булган.

Ләкин Гипатияне яратмаучылар, алай гына да түгел, аны дошман күрүчеләр дә булган. Кемнәр алар? Алар динчеләр. Чөнки аек акыллы, күп нәрсәне алдан күрүчән галим хорафатларга юл куярга, динчеләр кубызына биергә теләмәгән. Ә шәһәр башлыклары Гипатиянең сүзен зурлап тыңлый торган булганнар, ул әйткәннәргә һәрчак колак салганнар.

Ул чорда Искәндәрия яңа христиан диненең үзәге булып саналган. Динчеләр электән калган, ягъни мәҗүсилек чорында тупланган бар байлыкны юк итәргә, шул рәвешле халык күңелендә үзләренә юл ачарга омтылганнар. Алар борынгы осталарның, рәссамнарның гүзәл әсәрләрен һәлак иткәннәр, күп илләрнең бик сирәк очрый торган китапларын туплаган Искәндәрия китапханәсен ут төртеп яндырганнар.

Фән әһелләренә дә динчеләрнең нәфрәте көчле булган. Алар Гипатия хакында «җен ул, сихерче, ул кешеләрне боза», диган сүз таратканнар.

Аны бөтен шәһәр күз алдында, көпә-көндез үтерәләр. Китапханәдән кайтканын сагалап торалар да, ябык арбадан сөйрәп төшереп, кыйнарга, кулларын каерырга тотыналар, киемнәрен ерталар, бака кабырчыклары белән тәнен ерткалыйлар... Аннары һушсыз гәүдәне утка ягалар... Бу вакытта Гипатиягә 45 яшь була.


Аның турында китаплар язылган, ул күп галимнәрнең игътибарын җәлеп иткән. Соңыннан хәтта христиан дине үзе дә аны изгеләр исемлегенә кертергә маташкан. Христиан динендәге Искәндәрия Екатеринасы исемле изгенең биографиясе нәкъ менә Гипатиянең тормыш юлын файдаланып язылган.

УКУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА

Редакциягә хат язганда, кайбер укучыларыбыз үзләренең төгәл адресын күрсәтергә оныталар. Шуның аркасында без аларга хат яза алмыйбыз, ә барлык иптәшләргә дә журнал аша җавап биреп бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә редакциягә хат язган иптәшләрдән төгәл адресларын күрсәтүне үтенәбез.

Күп кенә иптәшләр төрле авыруларны дәвалау ысулларын сорап язалар. Авыру кешеләрне дәвалауда журнал аша ярдәм итеп булмый, чөнки һәр организмның үзенә генә хас үзенчәлекләре күп. Шунлыктан, берәүгә шифасы тигән даруның икенче кешегә зарар китерүе ихтимал. Һәр авыру кешене врач карарга, тикшерергә, аның үзенчәлекләрен ачыкларга, шуннан соң гына дәвалау ысулларын билгеләп, аларның шифасы тиютимәүне күзәтеп торырга тиеш. Авыру кешеләргә без врачка күренеп, ул кушканча дәваланырга киңәш итәбез.

МОДАЛАР



ТЫШЛЫКЛАР

Беренче бит. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисткасы Алсу Гайнуллина. Аның турындагы мәкаләне 18 нче биттән укыгыз.

Р. ЯКУПОВ фотосы.

Икенче бит. Надыйр Альмеев рәсеме.

Дүртенче бит. «Яз сулышы».

Р. МАНСУРОВ фотоэтюды.

Бәясе 20 тиен
Индекс 73002

